РАЗВЕДЧИК МАРТА
«Анда барыбыз да бертигез»
> 3

БЕРДӘМЛЕК
Туфан авыл өчен, безнең өчен яшәде, хәзер без аңа әҗерен кайтарабыз, дип яши мәрәтхуҗалылар
> 9

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Боларның барысы да эткә кидергән киемнәр кебек кенә...»
> 10

МИЛЛИ АККОРД
Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турында махсус проект
> 12

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 163–164 (29130–29131) | Чәршәмбе | 8 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

ИГЪТИБАР ҺӘМ КАЙГЫРТУ

Ил ташламас

Хәрби хәрәкәт ветераны статусы, 305 мең сумлык түләүне алу тәртибе һәм үзебезнекеләр турында кайгырту. Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чаралары турында сөйләделәр. Ярдәм алу тизрәк тә, җиңелрәк тә булсын өчен, махсус сайт та эшли башлаган.

tnv.ru

Моннан ары Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары гамәлдә булган ярдәм чаралары турында барлык мәгълүматны бер чыганактан таба алачак. «Үзебезнекеләр турында кайгырту» («Забота о своих») республика программасы кысасында шул ук исемдәге интернет-ресурс һәм чат-бот эшли башлады.

– Әлегә сынау рәвешендә эшләүче zabotasvo.tatar порталында Татарстанда гамәлдә булган барлык ярдәм чаралары тупланачак һәм системага салыначак, – диде Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева.

Аның сүзләренә караганда, әлеге чыганак хәрбиләр һәм аларның якыннарына белешмә алу яки документ җыю эшен җиңеләйтергә тиеш. Чөнки кирәкле бөтен мәгълүмат бер урында булгач, министрлык яки ведомстволар бусагасын кат-кат таптауның кирәге калмый.

Ярдәм чаралары алучылар сайтның эшенә бәйле үз тәкъдимнәрен дә җиткерә алачак. «Аларның барысы да исәпкә алыначак», – дип ышандырды Ләйлә Фазлыева.

Порталда ярдәм чараларын санап чыгу белән генә чикләнмичә, теге яки бу түләү турында тәгаен мәгълүмат, кирәкле документлар исемлеге дә тәкъдим ителәчәк. Ярдәм алу тизрәк тә, җиңелрәк тә булачак, кыскасы.

Россия Президенты Владимир Путин моңа кадәр билгеләп үткәнчә, дәүләт ярдәме махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен төп таяныч булып тора.

– Сүз матди ярдәм турында гына да бармый. Гәрчә ул кешелек яшәешенең нигезен тәшкил итсә дә. Игътибар, рухи ярдәм бик мөһим. Кешеләр илнең алар янәшәсендә икәнен, аларга ярдәмен, махсус хәрби операция кысасында алар үтәгән роль һәм миссияне аңлавын тоярга тиеш, – диде Илбашы.

– Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына төрле яклап ярдәм күрсәтә, – диде брифингта Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин.

Аерым алганда, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, тиешле документ нигезендә, 3896 сум күләмендә айлык түләү алырга хокуклы. Эдуард Вафин әйтүенчә, бүген республикада 2377 ветеран исәпләнә.

Моннан тыш, Россия Геройлары һәм сугышта һәлак булган Геройларның гаилә әгъзаларына 83496 сум күләмендә айлык түләү билгеләнә. Бу – иң зур түләү. Мобилизацияләнүчеләрнең йөкле хатыннарына, йөклелек чоры 180 көннән артмаган очракта, бер тапкыр 36278 сум акча түләнә. Хәрбиләрнең өч яшькә кадәрге балаларына 15548 сум күләмендә айлык пособие каралган.

Татарстанда яңа төр түләү дә гамәлгә керде. Исегезгә төшерәбез: республикада контракт буенча хезмәт итүчеләргә 305 мең сум күләмендә акча түләнә. Бер мәртәбә бирелә торган бу акчаны ике категориягә караган кешеләр алырга хокуклы. Беренчесе – Россия Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча чакырылучылар, икенчесе – хәрби хезмәткә чакыру буенча алынып, Татарстандагы хәрби комиссариатларда яки республикада урнашкан хәрби частьларда контракт төзүчеләр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Указы быелның 31 декабренә кадәр гамәлдә. Хәрбиләрнең контрактны 2023 елның 31 августыннан соң төзегән булуы да шарт.

– Әлеге төр түләү Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан хәрби комиссариатлардан килеп ирешкән мәгълүматлар нигезендә билгеләнә. Моның өчен гариза язарга кирәкми, – диде бу уңайдан Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова.

«Ватанны саклаучылар» фондының республикадагы бүлегендә генә дә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан 4 меңнән артык мөрәҗәгать кабул иткәннәр. Бу хакта брифингта фондның республикадагы бүлеге җитәкчесе Гүзәл Удачина әйтте.

Билгеле булганча, «Ватанны саклаучылар» фондын оештыру турындагы указны быел апрельдә Россия Президенты Владимир Путин имзалады. Ул хәрби хәрәкәтләр зонасын узган ветераннар һәм сугышчыларның гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә. Дәүләт фондының республикадагы бүлеге 1 июньнән бирле эшли.

Ахыры 2 нче биттә >

Кыйммәтчелек заманы

Татарстанда тотылган автомобильнең уртача бәясе 1,5 миллион сумнан артып киткән. «Авито» мәгълүматларына караганда, республикада яшәүчеләр арзанлы «ВАЗ (LADA) Kalina» машинасына (440 мең сум чамасы) өстенлек бирә. «ВАЗ (LADA) Granta» бераз кыйммәтрәк – 560 мең сум.

Чит илдә җитештерелгән «корыч ат»ларга килсәк, боларының бәясе 1 миллион сумнан артып китә. Әйтик, «Kia Rio» уртача 1,075 миллион тора. Тотылган «Volkswagen Polo»ны – 1,118 миллион, ә «Hyundai Solaris»ны 1,160 миллион сумга алырга мөмкин.

Уңайлы сәүдә

Татарстан интернет аша сату-алу күләме буенча Россия төбәкләре арасында 9 нчы урынга чыккан. ТАСС хәбәр иткәнчә, интернет-сәүдә өлкәсендә республиканың өлеше 1,9% тәшкил иткән. 2023 елның тугыз ае йомгакларына караганда, Мәскәү (18%) – беренче, Мәскәү өлкәсе (9,2%) – икенче, Санкт-Петербург (6,1%) – өченче урында. Беренче унлыкка шулай ук Краснодар (5,1%), Ростов (2,9%), Свердловск (2,6%), Түбән Новгород (2,2%) һәм Самара (2%) өлкәләре кергән. Исемлекне Красноярск крае (1,8%) төгәлләгән.

Гыйнвардан сентябрьгә кадәрге чор йомгаклары буенча, илдә интернет аша сәүдә күләме акчага салып исәпләгәндә барлыгы 4,3 триллион сум тәшкил иткән. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 23 процентка күбрәк.

Бума, ютәл!

Татарстанда быел сигез айда бума ютәл (коклюш) йоктыруның 217 очрагы теркәлгән. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, узган елның шушы ук чорындагыга караганда 43,4 тапкыр зуррак сан бу.

Гыйнвардан августка кадәрге чорда чирләүчеләр саны 100 мең кешегә 8,1 күрсәткечен тәшкил итә.

Исегезгә төшерәбез: бума ютәл, исеменнән үк аңлашылганча, бик нык йөткертә. Кайвакыт үпкә авыруына, хәтта үлемгә китерүе бар. Чирдән прививка ясатырга мөмкин.

Әйдә, ярминкәгә!

Татарстан фермерлары 9 ярминкә көнендә барлыгы 716 миллион сумлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, шәһәр халкы көзге ярминкәләрдә чама белән 1,5 миллион данә йомырка, 7 мең тоннага якын яшелчә, шул исәптән 4306 тонна бәрәңге, 1522 тонна суган, 439,5 тонна сөт, 501,2 тонна шикәр комы, 697 тонна ит (шуның 402,3 тоннасы – сыер ите) сатып алган. Сәүдәне оештыруда 35 район катнашкан, 8578 берәмлек транспорт җәлеп ителгән.

Авыл хуҗалыгы ярминкәләре, 9 сентябрьдә ачылып, 23 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Алар һәр атна саен Казанда – 14 урында, Чаллы һәм Яшел Үзән районнарында – икешәр, Түбән Камада 3 урында уздырыла. Көзге сәүдә 26 районда атнаның төрле көннәрендә үткәрелә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Һава торышы

Табигать саташуы

Татарстан Гидрометеоүзәге мәгълүматларына караганда, алдагы атнада җылы көннәр сакланачак әле.

Әмма белгечләр, Себер циклонының активлашуы аркасында һава торышы бозылачак, ди. Кыскасы, яңгыры да явар, томаны да төшәр, җиле дә чыгар, дип вәгъдә итәләр. Атна дәвамында һава температурасы төрлечә булачак. Яңгырлы көн янында җылы, матуры да кәтелә. Синоптиклар башка елларга караганда быелгы ноябрьнең нормадан 4 градуска җылырак икәнен искәртә.

Ноябрьгә карап, башка айларның ничек киләсен белеп була, ди Россия Гидрометеоүзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд.

– Кыш айлары үзгәрүчән булачак. Бер салкынайтып, бер җылытып торачак, – ди ул.

«Фобос» һава торышы үзәге белгече Евгений Тишковец та киләсе кышның көйсез булачагын вәгъдә итә. Ул салкыннардан соң көннәрнең җылыначагын, кардан соң бозлы яңгырлар явачагын фаразлый.

Мондый һава торышы авыл хуҗалыгына зыян салмасмы? Арча авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Раил Шакирҗанов әйтүенчә, борчылыр сәбәп юк. Баш агроном, көннәрнең җылы һәм яңгырлы булуы басулар өчен бик уңай, ди.

– Җиргә төшкән явым-төшем туфракка сеңеп бара. Җирнең туңмыйча торуы яхшы, – ди ул. – Әгәр инде явым-төшем булмыйча, туңдырып куйса, ул чакта уҗымнарга зыян киләчәк.

Көннәрнең әле җылы, әле яңгырлы, җилле-давыллы торуы сәламәтлеккә начар йогынты ясый. Казан федераль университеты профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев та шулай ди.

vk.com

– Атна ахырына кадәр һава торышы җылы булачак. Татарстанда Атлантик циклон хакимлек итә. Әмма бу – аномалия. Әлеге вакытта инде һава температурасы минус булырга тиеш, – ди ул.

Без аннан күптән түгел күк йөзендә күзәтелгән «Төньяк балкышы» хакында да сораштык.

– Әлеге күренешнең сәбәбе – җирдәге көчле магнит давылы. Әнә шуңа да күк йөзенең алсулануын күзәттек. Кояшның актив булуы да мондый күренешләрне китереп чыгара. Кемнәрдер җир тетрәргә дә мөмкин дип язалар. Әмма бу дөрес түгел. Җирнең кайчан тетрисен берәү дә алдан әйтә алмый, – ди профессор.

Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче халык синоптигы Әмир Шәрипов исә, үз гомеремдә мондый җылы ноябрьне күргәнем юк иде, ди.

– Чын салкыннар ноябрь ахырында булачак, дип уйлыйм. Кыш үзенекен итмичә калмас: салкыны да булыр, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Валентина МАТВИЕНКО, Федерация Советы Рәисе:

Мин Россиядә Бәхет министрлыгы оештыру турында хыялланам. Әлеге ведомствода бөтен карарлар, законнар: «Ә хөкүмәтнең бу яңа законы яки яңа карары кешеләрне бәхетлерәк итәчәкме?» – дигән сорауга җавап эзләү аша узар иде.

(«Знание. Первые» форумында әйткән сүзләре)

ТАТАРСТАНДА – ОНЛАЙН ХЕЗМӘТЛӘР

Республиканың дәүләт хезмәтләре порталыннан файдаланучылар >> **3 млн** кеше

260 млн электрон хезмәт күрсәтелгән

Ел азагына фараз – **350 млн**

Цифрлы технологияләр ярдәмендә халыкның **38 млн** сәгать һәм **9 млрд сум** акчасы янга калган

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЕВРОПА РЕЦЕССИЯГӘ БАТКАНДА

Глобаль икътисадның төп уенчыларыннан берсе булган Европа рәсми рәвештә рецессия сазлыгына батып бара. Көнбатыш икътисадының кәефсезләнүе күптән барса да, бу хакта игълан итүдән сакланалар иде. Хәзер карт континентның икътисад локомотивы булган Германиядә җитештерүнең түбәнәюен яшерүдән туктадылар.

Илдә энергия чыганакларына ихтыяҗ илле еллык минимумда. FGE консалтинг компаниясе Германиянең сәнәгать базасына, бигрәк тә энергияне күп таләп итүче тармакларга элекке дәрәҗәгә күтәрелү бик катлаулы булачак, дип белдерә. Икътисадның түбән тәгәрәве бюджет дефицитын көчәйтә. Европа Үзәк банкы да процент ставкасын күтәрде. Бюджет өчен бурычка акча табу катлауланды. Шольц җитәкләгән партия илдә иң бай немецларга вакытлы «кризис взносы» кертү инициативасы белән чыкты. Германия әлегә «Зур җиделек» илләре арасында рецессия башланган бердәнбер дәүләт булып санала иде. Әмма иң соңгы хәбәрләр Англиядә дә эшләр шәп түгеллеген раслый.

Көнбатышка бу юлы кризистан чыгу җиңел булмаячак. Бердән, барлык сыналган ысуллар инде файдаланылып бетте, күпләп акча басу да, арзанлы кредитлар өләшү дә булышмый. Икенчедән, глобаль базар урынынына фрагментлашу дип аталган нәрсә килә: илләр башкалар өчен үз базарларын ябалар. Бу чыгымнарның артуын, бәяләрнең күтәрелүен генә вәгъдә итә. Өченчедән, Африка илләре Көнбатышның чимал кушылдыгы булудан туктарга тели. Быел гына да, мәсәлән, французларга берничә Африка иленнән табан ялтыратырга туры килде. Европа лидерлары, арзанлы чимал эзләп, Урта Азия республикаларына ешлыйлар. Көньяк Африка Республикасы президенты Сирил Рамафоса: «Африка илләре Көнбатыш өчен чимал икътисады статусын сакларга теләми һәм үз сәнәгатьләрен үстерергә ниятли», – дип чыгыш ясады.

Bloomberg агентлыгы: «Европада бөек торак кризисы башланып кына килә», – дип яза. АКШ икътисады әлегә үзен чагыштырмача яхшы хис итә. Евросоюз икътисады хәзер, долларга күчереп исәпләгәч, Америка икътисадының 65 процентын тәшкил итә. Ә 2013 елда бу сан 91 процент булган. Әмма американнарга сөенергә сәбәп зур түгел, проблемалар анда да туплана. Ипотекага ихтыяҗ кимеп, 1995 елның февралендәге минимумга калган. Дәүләт бурычын түләү өчен елга бер триллион долларга якын акча таләп ителә башлаган. Өч ел эчендә бу сан ике тапкыр арткан. Ә салым җыемнары шул чор эчендә 20 процентка гына үскән. Зур кризисның тозагына эләкмәгән бер ил дә юк бүген.

Россиядә

ШАТЛЫК БЕЛӘН ХӘСРӘТ АРАСЫНДА

Бер фанфаралар кагабыз, бер борыннар салына. Россия икътисадында хәлләр шулайрак. Тукайны бераз үзгәртсәк, кризис турында россияле: «...мин синдә бер шатлык, бер хәсрәт күрәм», – дип әйтә алыр иде. Шатлык шунда: безгә дошман булган һәм санкцияләр керткән икътисадлар суган суы суыра. Хәсрәтнең исә үз сәбәбе: алар артыннан без дә шуны ук кабатлаячакбыз.

Кризис чимал икътисадларына бәяләр төшү белән яный. «Нефть инәсеннән төштек», – дип кычкырсак та, бар бюджет һәм импорт «кара алтын» бәясенә бәйләнгән. Агымдагы вазгыятьтә барысы да ал да гөл күренә. Сум курсы хөкүмәт теләгән чикләрдә ныгыды. Дөрес, моның өчен популяр булмаган һәм киләчәктә икътисадны тез чүктерәчәк чараларга барырга туры килде. Иртәгә өчен ишәк кайгырган дигән принцип белән яшәргә мәҗбүрбез. Силуанов әйтә бит: «Доллар курсына азрак игътибар итегез», – ди. Киләчәктә курс уйнавы булачак, дип аңлап була ул сүзләрне.

Бүген статистиканың матур саннары белән күңелгә шатлык тутыра алабыз. Октябрьдә нефть сатудан кергән салымнар күләме югарыга үрмәләгән. Файдалы казылмалар салымы һәм таможня пошлиналары 1,21 триллион сумга җиткән, ягъни 12 миллиард доллар тирәсе булган. Бу 2022 һәм 2021 еллар октябрьләренеке кадәр диярлек. Ә быелгы гыйнвар – июль айларыныкы белән чагыштырганда 50 процентка артык. Күрер күзгә бик яхшы күрсәткеч, ләкин аның үзенең серле эчке кухнясы бар. Әлегә саннар белән куанып торыйк.

«Росрыболовство» дигән оешма җитәкчесе Шестаков безне шатландыра: кызыл уылдык һәм горбуша балыгына бәяләр төшә, ди. Бәя төшү балык тоту күләме артуга бәйле. Балыкчылар үз бәяләрен бер ярым тапкыр төшергән инде. Беләм: газета укучылар көн саен кызыл уылдык ашап утырмый, шулай да бәя төшү күңелле.

Россия икътисадының ыргылышлы үсеше турындагы саннарга сөенергә өлгермисең, бер мичкә балга бер кашык дегет тамызучы табыла. Рәсми федераль газеталарның берсе октябрьдә йөк ташуның кискен кимүен хәбәр итә. Статистика теләсә нинди үсеш санын күрсәтә ала, әмма йөк ташу кимегән икән, шикләнми әйтеп була: икътисад чүгә. Йөк ташу күрсәткече исә үткән ел октябре белән чагыштырганда 3,5 процентка кимегән.

Росстат, җан башына айлык керем 47,5 мең сум дип белдерсә, Югары икътисад мәктәбе белгечләре 24,9 мең генә ди. Сөенәсең килсә, Росстатны укы, көенәсең килсә, башкаларны, чынбарлыкны беләсең килсә, үз кесәңә кара.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ТАРИХИ СӘФӘР

tatarstan.ru

Бу елның алты аенда Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше утыз процентка арткан. Күрсәткечләр тагын да үсәргә мөмкин. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Каракалпакстанга эш сәфәре барышында уртак эшчәнлекнең тәгаен юнәлешләрен билгеләделәр.

Билгеле булганча, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстанның Каракалпакстан Республикасына эш визиты белән барды. Биредә ул Каракалпакстан парламенты Рәисе Аманбай Орынбаев белән очрашты. Чарада Үзбәкстан Республикасы Президенты Киңәшчесе Турсинхан Ходайбиргәнов та катнашты.

– Бүгенге очрашуны Россия һәм Үзбәкстан төбәкләре арасындагы хезмәттәшлекнең ныгуының ачык мисалы буларак кабул итәбез. Бу – безнең өчен тарихи сәфәр, – диде Аманбай Орынбаев.

Ул искәртеп үткәнчә, бүген Россия Каракалпакстанда җитештерелгән товарларны төп кулланучы булып тора. Татарстан белән хезмәттәшлекне тагын да ныгыту өчен, Аманбай Орынбаев төбәкара эшче төркем оештырырга да тәкъдим итте.

Сөйләшү барышында Турсинхан Ходайбиргәнов Шәүкәт Мирзиёевның җылы сәламләвен дә җиткерде. Аның әйтүенчә, Үзбәкстан башлыгы әлеге очрашуга зур әһәмият бирә һәм төбәкләр арасындагы хезмәттәшлекне үстерүнең яңа мөмкинлекләрен күрә.

– Без Россия белән Үзбәкстан арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр кысасында сезнең ил белән хезмәттәшлекне үстерүгә зур әһәмият бирәбез. Бу эштә ике ил Президентлары Владимир Путин һәм Шәүкәт Мирзиёевның өлеше зур, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 290 миллион доллардан да артып киткән. Быелның алты аенда гына да әлеге күрсәткеч 147,7 миллион долларга җиткән. Үсеш – 30 процент. Рөстәм Миңнеханов төбәкара эшче төркем булдыру фикерен хуплады.

Очрашу барышында Каракалпакстан җитәкчелеге Татарстан тәҗрибәсен һәм Чирчикта тормышка ашырылучы уңышлы проектларны исәпкә алып, махсус икътисадый зона төзү тәкъдимен дә җиткерде. Бу уңайдан яклар, республика делегациясенең Каракалпакстанга эш визиты барышында танышкан мәйданнарның мөмкинлекләре бәяләнәчәк, дигән фикергә килде.

Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханов Нукус шәһәрендә «Prime electric engineering» предприятиесендә булды. Завод Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев тәкъдиме белән төзелгән. Биредә көнкүреш техникасы җитештерелә. Элек ул иске заводның буш бинасы булган. Үзбәкстан җитәкчелеге гамәлгә керткән ташламалы программалар ярдәме белән ремонт ясаганнар, җайланмалар сатып алганнар һәм җитештерүне җайга салганнар. Рөстәм Миңнехановка җитештерү линиясен күрсәттеләр. Шулай ук, Каракалпакстандагы салым ташламаларының үзенчәлекләре турында сөйләделәр.

Татарстан Рәисе Каракалпакстанның элеккеге территориаль мамык терминалы биналарын да карады. Ул Нукус үзәгеннән ерак түгел урнашкан. Рөстәм Миңнеханов «Алабуга» махсус икътисадый зонасы һәм «Химград» АҖ җитәкчелегенә бу территориянең мөмкинлекләрен өйрәнергә һәм биредә тормышка ашырырга мөмкин булган проектларга бәя бирергә кушты.

– Энергия ресурслары булу, җитәрлек мәйданнар, отышлы салым режимы һәм иң мөһиме – эшче кадрлар. Әнә шул база булса, эшләп була, – диде Татарстан Рәисе.

Сан

Каракалпакстан – Үзбәкстан составындагы суверен республика. Биредә якынча 1 миллион 990 мең кеше яши. Башкаласы һәм иң зур шәһәре – Нукус. Каракалпакстан белән җирле парламент Рәисе Аманбай Орынбаев җитәкчелек итә.

Игътибар һәм кайгырту

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Мондый фонд ил тарихында тәүге тапкыр оешты. Бөек Ватан сугышыннан соң да, Әфганстан, Чечня сугышларыннан соң да бу дәрәҗәдәге ярдәм юк иде, – диде Гүзәл Удачина. – Казандагы төп үзәктән тыш, Татарстанның 19 шәһәре һәм районында 45 социаль координатор эшли. 1 июньнән бирле безгә 4140 кеше мөрәҗәгать итте. Ярдәм сорап, махсус хәрби операциядә катнашучылар үзләре дә, аларның гаилә әгъзалары да килә. Аларның һәркайсына хәлдән килгән кадәр булышырга тырышабыз.

Гүзәл Удачина сүзләренә караганда, сугышчыларны һәм аларның якыннарын акчалата түләү мәсьәләсе ешрак борчый. «Мәсәлән, яу кырында яралануга бәйле түләүләргә ачыклык кертүне сорап мөрәҗәгать итәләр», – диде ул. Шулай ук хәрби хәрәкәт ветераны таныклыгын алуга бәйле сораулар да күп. Бу хакта сөйләгәндә, Гүзәл Удачина шәхси хәрби кампанияләрдә катнашучыларның да әлеге төр таныклыкны алырга хокуклары булуын искәртте. Аерым алганда, «Вагнер» хәрбиләренә таныклык алырга «Ватанны саклаучылар» фонды ярдәм итәчәк.

– Хәрби хәрәкәт ветераны статусы алуга бәйле сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе – шәхси хәрби кампанияләрдә катнашучылар. Аларга бәйле вазгыять катлаулы иде. Бүген ул закон белән көйләнгән. Әмма «Вагнер» шәхси хәрби кампаниясен алсак, биредә бу эш белән аерым шөгыльләнә алучы оешма юк. Шуңа күрә хәрбиләргә «Ватанны саклаучылар» фонды булышачагы турында карар кабул ителде. Без, документларны җыеп, РФ Оборона министрлыгына җибәрәчәкбез, – диде Гүзәл Удачина.

Солдатларга ярдәм күрсәтүдә исә теләге булган һәркем катнаша ала. «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте координаторы Ринат Фазыйлов әйтүенчә, быелның 6 ноябренә алынган мәгълүматларга караганда, алар республика складларында хәрбиләргә дип 224 меңгә якын данә товар җыйган. 2022 елның октябреннән 2023 елның сентябренә кадәр вакыт аралыгында якташларыбыз хезмәт иткән 12 хәрби бүлекчәгә ярдәм күрсәткәннәр. Махсус хәрби операция зонасына бар җирдән үтә алучы биш машина озатканнар. Якын арада тагын шундый ике автомобиль җибәрергә ниятлиләр. Әле күптән түгел генә, 7 октябрьдә Татарстан егетләре хезмәт иткән 1231 нче полкка 2,5 мең тонналы ярдәм киткән. «Ноябрь ахырында чираттагысын җибәрәчәкбез», – диде Ринат Фазыйлов.

Эльвира ВӘЛИЕВА

АЛТЫН ТАВЫК

Россиядә тавык итенә бәяләр уртача 28,5 процентка артты. Хәзер аның бер килограммы уртача 220 сумнар тирәсендә тирбәлә. Ашлык бәясе шул ук калды, ә йомырка һәм тавык итенеке өскә сикерде. Сәбәп нидә соң? Белгечләр белән әлеге сорауга җавап эзләдек.

Тегә яки бу продуктка бәя күтәрелү белән безне инде әллә ни гаҗәпләндереп булмый анысы. Тик моңа кадәр башка продукция хаклары артса да, кош итенең бәясе гадәттә тотрыклылык саклап килә иде. Шуңа күрә күпләр нәкъ менә әлеге төр иткә өстенлек бирде. Тик соңгы айларда анысы да сынатты.

Росстат мәгълүматлары буенча, быелның гыйнварыннан сентябренә кадәр тавык итенең бәясе 25,4 процентка, ягъни 176,25 сумнан 221,02 сумга кадәр арткан. Кайбер төбәкләрдә ул тагын да ныграк кыйммәтләнгән. Дөрес, Россия Президенты Владимир Путин белән очрашу вакытында авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев тавык итенә бәя төшә башлавын әйтте. Шул ук вакытта 26 октябрьдә министрлык эчке базарда әлеге төр продуктка кытлык булдырмау һәм бәя артуны туктату өчен аерым төр кош итен һәм йомырканы вакытлыча читкә чыгаруны тыйды.

Әлеге үзгәрешләрне Казанда яшәүче Людмила һәм Светлана аеруча нык сизгән. Апалы-сеңелле Демьяниналарның авырулары бик җитди. Пенсияләренең күпчелек өлеше даруларга һәм фатир өчен түләүгә китеп бара. Ашауны исә мөмкин булганча кысарга туры килә.

– Без бары тик тавык ите генә ашыйбыз. Башка ит яратмаганнан түгел, ә бәясе арзанрак булганга күрә. Тик августтан безнең өчен анысы да күтәрә алмас дәрәҗәгә җитте. Моңа кадәр пенсия килгәч, ике-өч тавык ала идек тә шуны бер айга җиткерә идек, хәзер билләрне тагын да кысыбрак бәйләргә туры килә. Шуңа күрә безнең табында ит – сирәк була торган сый, – ди Людмила Демьянина.

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белгечләре «ВТ» хәбәрчесенә белдерүенчә, Татарстан үзен социаль әһәмиятле ризыклар (кош ите, йомырка, сыер һәм дуңгыз ите, бәрәңге, сөт һәм сөт продуктлары, шикәр, көнбагыш мае, он) белән тәэмин итә. Тик министрлык та соңгы айларда, бигрәк тә соңгы берничә атнада тавык итенә һәм йомыркага бәя артканны инкарь итми. Әйтик, Татарстанстатның 30 октябрьгә булган мәгълүматлары буенча, тавык йомыркасы 84,24 сум тора. Аннан алдагы атна белән чагыштырганда, хаклар 2,71 сумга күтәрелгән дигән сүз. Тавык ите белән дә шул ук хәл. 23 октябрьдә бер килограмм тавык ите 210,11 сум торса, бер атна эчендә ул 212,48 сумга җиткән.

– Бәя арту компонентларның кыйммәтләнүенә, чалу цехларындагы җиһазларны карап тору һәм төзекләндерү, логистика чыгымнарының артуына бәйле. Шулай ук кош гриппы профилактикасы өчен ветеринария чыгымнары да бәяләр артуга китерә, – диде министрлыкның матбугат үзәге.

Шунысын да әйтергә кирәк: соңгы өч елда авыл хуҗалыгы оешмаларында, фермер хуҗалыкларында терлекләрне һәм кош-кортны терелә́й сату – 4,3 процентка, йомырка җитештерү 3,5 процентка арткан. Татарстан эшкәртү өчен кош сату буенча Россиядә – унберенче, ә йомырка җитештерү буенча тугызынчы урында тора.

– Без бер кешегә тиешле норманы арттырып үтибез. Әйтик, җан башына елына 73 кг терлек һәм кош ите кирәк. Республикада ул 29 процентка күбрәк җитештерелә. Шул исәптән кош итенең бер кешегә тиешле нормасы 31 килоны тәшкил итә. Ә җитештерү – 42 кг. Норма буенча бер кешегә 260 данә йомырка тиеш булса, җитештерү 35 процентка күбрәк, ягъни 294 данә туры килә, – дип исәпләп чыгарды министрлык вәкиле.

Тавык ите артуга төп сәбәп һәрвакыт ашлыкка бәя күтәрелү була торган иде. Ул кошлар өчен катнаш азыкның 70 процентын алып тора. Ә катнаш азык ит җитештерүнең үзкыйммәтенең 70–80 процентын тәшкил итә. Бу яктан караганда, бәяләр өскә сикерергә тиеш түгел дә кебек, тик «Мусабай» фермер хуҗалыгы җитәкчесе Айгөл Ханова фикеренчә, ит һәм йомыркага бәя катнаш азыкка хак артуга бәйле булырга мөмкин.

– Ашлыкка бәя шул ук калды, ә катнаш азыкка күтәрелде. Ягулык, электр энергиясе, кредитларга процент ставкалары артты. Болар да үзкыйммәткә йогынты ясый. Моннан тыш, бер тәүлеклек бройлер 20 сумга кыйммәтләнде, – диде ул.

Шулай да фермер хуҗалыгы мөмкин булганча бәяләрне йөгәнләргә тырыша.

– Бөтен җирдә тавык итенең бәясе артты дисәләр дә, бездә алар узган елдагыча калды. Фермер продукциясен узган ел да 200 сумнан саттык, быел да шулай ук. Әйе, чыгымнар артты, без азрак акча эшли башладык, тик бәяләрне күтәрмәдек. Базар бәяләре белән кызыксынганым юк. Бәяләрне бәлки арадашчылар яки фабрикалар арттыргандыр. Чөнки соңгы вакытта безнең продукциягә ихтыяҗ артуын сизәбез, – диде Айгөл Ханова.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сан

Россиядә тавык итенә (суытылган һәм туңдырылган) уртача бәяләр ничек үзгәрде?

10 гыйнвар, 2022 ел	**182 сум**
1 апрель, 2022 ел	**187 сум**
1 июль, 2022 ел	**187,5 сум**
3 октябрь, 2022 ел	**181 сум**
9 гыйнвар, 2023 ел	**178 сум**
3 апрель, 2023 ел	**170 сум**
3 июль, 2023 ел	**194 сум**
3 октябрь 2023 ел	**229 сум**

Татарстанда уза торган ярминкәләрдә йомырка бәяләре (сумнарда): СО – **105**, С1 – **95**, С2 – **85**.

(Росстат мәгълүматлары буенча)

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ватан хакына

РАЗВЕДЧИК МАРТА МАКАРОВА:

«БАЛАЛАРДАН ХАТЛАР АЛГАЧ, КҮЗДӘН ЯШЬ КИЛӘ»

Махсус хәрби операциядә разведчик булып хезмәт итүче Марта Макарованы күптән түгел башкалада узган «Многоликая Россия» журналистлар бәйгесенә җиңүчеләрне котларга чакырганнар иде. Тантанадан соң аның белән аралашырга да җай чыкты. 23 яшьлек студент укырга да, хезмәт итәргә дә ничек өлгерә икән? Хатын-кызга яу кырында авыр түгелме? Марта киләчәккә планнары белән уртаклашты.

Мартаның хәрби операциягә китүенә елдан артык. Өлешчә мобилизация башлангач, Тамбовтагы разведка батальоны командиры, дөресрәге, танышы чакырган аны. Кызның хәрби булу теләген күптән белгән чөнки. Аның белән ярышларда очрашкалаган. Казанның 13 нче мәктәбендә кадетлар сыйныфында укыган Марта. Анда разведчиклар турында сөйләгәннәре аеруча исендә калган. Коралдан ату буенча ролик та төшергәннәр. Шуның өчен хәрби тема аның өчен ят түгел. Физик яктан сәламәт. Спортның йөзү, ату кебек төрләре белән шөгыльләнгән. Шуңа күрә хәрби операциягә китәр өчен күп уйланырга туры килми. Аннан бит иптәш кызларыннан башка, «бара күрмә» дип үгетләүчесе дә юк. Марта балалар йортында тәрбияләнгән. Гаиләсе дә, туганнары да юк, ялгыз яши. Кыскасы, Марта үзен яуда кирәгрәк дип хис иткән. Тик укуы бар бит әле. КФУның чит телләр факультетында тәрҗемәчелеккә укый ул. Киләчәктә немец теле белгече булачак.

– Уку буенча проблема юк. Укытучыларым хәлемә керәләр. Өстәмә биремнәр алам, онлайн да укыйм. Сессияләрне вакытында бирәм. Әле ялда идем, икенче атнага фронтка китәм. 1 ноябрьдә туган көнем иде. Аны бәйрәм итеп тормадым. Яудагы дусларны сагындым. Берничә ай хезмәт итеп, кире кайтырга исәп. Аннан бар көчемне укырга бирергә җыенам. Алда иң мөһиме – белем алу, – ди 3 курс студенты Марта Макарова.

Нәфис зат яудагы кыенлыкларга ничек түзә икән? Разведчик кызның җитезлеге җитәме? Ядрәләр шартлаганда, йөрәге ничек түзә? Әле бит бизәнү, матур күлмәк турында да онытып торырга кирәк.

– Хәрби операциядә катнашучы кызлар бик аз. Булганнары да солдатларга медицина хезмәте күрсәтә. Нигә аптырыйсыз, фронтта нинди җенестән булуың мөһим түгел. Анда барыбыз да бертигез. Үземдә ирләр холкы дип санамыйм. Курку хисе юк, ә менә Ватаным белән горурлану бар. Гомеремне илем өчен бирергә әзер. Бу – гади сүзләр генә түгел. Без нацизм, терроризм чәчәк аткан җирләрне дошманнардан азат итәбез. Бер гаепсез гомере өзелгән балалар, әниләр өчен көрәшәбез, – ди Марта, ялкынланып.

Билгеле, башта интернетсыз, су һәм ризыксыз тормышка ияләшү җиңел булмый аңа. Коры паек белән туклананалар. Анысы да әлексә әле... Блиндажда, җир өстендә йокы капчыкларында йоклыйлар. Марта әйтүенчә, хатын-кызга сугышта җиңел түгел. Юынырга душ та юк.

Беренче көннәре ничек үткән? Бер-ике атна хәрби әзерлек үткәннән соң, Мартаны Луганскига Купянское юнәлешенә беренче линиягә разведчик итеп җибәрәләр. «Корал белән яхшы эш итәм», – ди ул. Позывное – Алекс. Хәзер Херсон юнәлешендә хезмәт итә.

Башта Марта турында, фронтка егет эзләп килгән, дип уйлаучылар да булган. Әмма үзен лаеклы итеп күрсәткәч, хезмәттәшләре фикерен үзгәрткән. Әлегә гаилә корырга иртәрәк дип саный. Йөрәге дә буш икән. Кайчак каядыр барырга тәкъдимнәр дә булуын яшерми. «Кая барасың, күрше окопкамы?» – дип елмая әңгәмәдәшем. Андагы солдатлар аңа абыйлары кебек якын. Бер гаилә кебек яшиләр икән. Бер-берсенә абый, сеңел дип дәшәләр.

> Разведчик булу өчен зирәклек, җитезлек кирәк. Табигать шартларына тиз генә ияләшермен дип уйламаган идем. Урманда да адашмыйм икән. Һәр сукмак, эзне истә калдырам. Биремнәр булмаса, блиндажда утырабыз.

Аның әйтүенчә, яу кырында төрлесен күрергә туры килә. Засадада торганда пуля эләккән иптәшен өстерәп чыгарган. Аннан солдатны пунктка озатканнар, ул хәзер госпитальдә дәвалана икән. Батыр ярасыз булмый. Марта үзе дә яраланган. Шулай бервакыт урманнан барганда, атышлар башлана һәм кызга минометтан ядрә кыйпылчыгы тия. Медиклар беренче ярдәм күрсәтә. Шуннан соң аны дәваланырга кайтарып җибәрәләр. Мартаны «Батырлык өчен», «Хәрби казанышлар өчен» («За боевые заслуги») медальләре белән бүләкләгәннәр.

«Яшьләрдә ватанпәрвәрлек хисе бармы, аны ничек тәрбияләп була?» – дип тә сораштык Мартадан.

– Яшьләрдә патриотизм хисе җитә дип уйлыйм. Мәктәпләрдә дә бу хакта гел сөйләп торалар бит. Бу хисне ничек арттырырга кирәклеген әйтә алмыйм. Ниндидер үрнәк гамәл, эшләр беләндер инде. Безгә балалар хатлар яза. Рәсемнәр ясап җибәрәләр. Менә шул хатларны алгач, күзләргә яшь килә. Бу да – патриотик тәрбия бит инде, – ди Марта Макарова.

Сәрия МИФТАХОВА

Ярдәм янәшә

Татарстан күчтәнәче

Кукмара тушенкасы, бавырсак, лимонад, тозланган яшелчәләр. Лисичанск һәм Рубежный шәһәрләрендәге кибет киштәләрендә Татарстанда җитештерелгән продукция сатыла хәзер. «Татарстанда җитештерелгән» дигән сүзе бар: димәк, сыйфат өчен борчыласы түгел.

Татарстан шефлыгында булган шәһәрләрдәге тормышка җан өрү өчен, республика барысын да эшли. Халыкның кибеткә булган ихтыяҗы да көн кебек ачык. Шуңа күрә кибет киштәләре буш торырга тиеш түгел.

– Безнең карамакта булган шәһәрләрдә тормыш бөтен булсын өчен, Татарстан җитештерүчеләре продукция ассортиментын киңәйтергә тырышачак, – дип билгеләп үткән иде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та.

Моны инде сизә дә башлаганнар. Әнә шушы шәһәрләрнең берсендә яшәүче ханым республиканы мактап туймый.

– Мин бу кибеткә еш йөрим, Татарстан продукциясе артканын сиздем. Барысы да бик сыйфатлы һәм тәмле. Татарстанга рәхмәт! – ди республика шефлыгындагы шәһәрләрдә яшәүче ханым.

Чынлап та, республикадан килгән ассортимент шактый киң: татлы сулар да, тәм-томнар да (әйтик, чәкчәк, киптерелгән җиләк-җимешләр), тозлы ризыклар да бар. Өстәвенә көн саен диярлек Татарстан районнарыннан һәм шәһәрләреннән гуманитар йөк җибәрелеп тора, республика уңганнары бу шәһәрләрне кышка әзерли, социаль учреждениеләр биналарын торгыза. Кыскасы, бу җирлекләргә дә тормыш кире кайта.

Әле күптән түгел генә Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров та Татпотребсоюзның Лисичанск шәһәрендәге сәүдә челтәрләре белән килешүе барлыгын әйтте.

– Кирәк булса, безгә гаризалар җибәреләчәк һәм аларга продукция китереләчәк, – диде ул. – Хәзерге көндә авыл хуҗалыгы предприятиеләре махсус хәрби операция зонасына 300 тоннага якын азык-төлек һәм шәхси гигиена әйберләре җибәрде. Гуманитар йөккә шикәр, он, ярма, консерв, каһвә, чәй, су һәм башка продукция керә. Республиканың бер генә предприятиесе дә бу эштән читтә калмады. Кемдер машиналар җибәрә, кемдер – запас частьлар, генераторлар, җылыту өчен мичләр, кемдер – акча.



Күңел эше

Биш көндә 7 тоннадан артык кирәк-ярак. Кыска гына вакыт аралыгында республикада яшәүчеләр Газзә секторы халкына әнә шулкадәр гуманитар ярдәм җыйган. Бүген – 8 ноябрьдә – гуманитар ярдәм җыюның соңгы көне. Аннары бу йөкне Мисырга озатачаклар.

Билгеле булганча, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча 3 ноябрьдән республикада Газзә секторы халкына гуманитар ярдәм җыю үзәге оештырылды. Татар мөселманнары Диния нәзарәте белән Мисырның «Кызыл ярымай» оешмасы зыян күрүчеләргә кирәкле азык-төлек һәм кирәк-ярак исемлеген төзеде. Халыктан азык-төлек, шәхси гигиена әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары кабул итәләр. Тулы исемлек ярдям.рф сайтында урнаштырылган.

Артык зур булмаган кирәк-яракларны «Ярдәм янәшә» хәрәкәтенең офисына (Патрис Лумумба урамы, 4 йорт, 112 кабинет), зур әйберләрне Мәҗит Гафури урамы, 4б йорт адресы буенча китерергә мөмкин. Ярдәм янәшә фонды координаторы Ринат Фазылов сүзләренә караганда, гуманитар ярдәм итү пунктларыннан халык өзелми.

– Һәр 10–15 минут саен безгә гуманитар ярдәм төялгән йөк машиналары килеп тора. Мөселман кардәшләребез генә түгел, төрле диндә, төрле вазыйфада булган һәркем ярдәм итәргә ашыга. Казаннан, Татарстан районнарыннан гына түгел, Россиянең башка төбәкләреннән Газзә халкына кирәк-ярак китерүчеләр бар, – ди ул.

Ил-көнгә килгән кайгы халыкны аеруча берләштерә шул. Моның шулай икәненә махсус хәрби операция башлангач та инандык. Республика халкы батыр егетләребезне әле дә ярдәмнән өзми. Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Айгөл Сабирова сүзләренә караганда, Газзә халкына гуманитар ярдәм җыю үзәге ачылгач та, Татарстан халкы кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә ашыккан.

– Газзә халкына ярдәм җыю турында тәкъдимнәрне республика халкы әледән-әле җиткереп торды. Штабта көн саен 15–20 волонтер кизү тора. Ярдәм итәргә теләүчеләр саны артканнан-арта бара, – ди министр урынбасары.

Гуманитар ярдәм җыюга Татарстан Диния нәзарәтенең «Зәкят» фонды да зур өлеш кертте. Биш көн эчендә биредә Газзә секторы халкына 27,5 млн сумлык ярдәм җыелган.

– Акчалата ярдәмнән тыш халык актив рәвештә подгузник, салфетка, балалар ризыгы, гигиена чаралары, токмач, теш щёткасы, теш пастасы кебек кирәк-ярак та алып килә. «Зәкят» хәйрия фонды бары хәләл ризыклар гына кабул итә. Моннан тыш, китерелгән барлык әйберләр яңа булырга тиеш. Халыкара гуманитар ярдәм күрсәтүнең шартлары, регламентлары, кагыйдәләре бар. Шуңа бәйле рәвештә барысы да яңа, лицензияле, сатып алынган булырга тиеш. Гуманитар йөк Газзә секторына үзәкләштерелгән рәвештә Мисыр һәм Газзә секторы чигендәге «Рафах» чик буе үткәрү пункты аша кертеләчәк, – дип хәбәр итәләр Диния нәзарәтеннән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЗУРЛАРНЫКЫ КЕБЕК КИРӘК!

«АЛДЫНГЫЛАР СОВЕТЫ»НДА БАЛАЛАР НИ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘЧӘК?

Белем һәм тәрбия

Чын тавыш бирү, чын сайлау алды кампаниясе, чын лидерлар. Илкүләм «Алдынгылар хәрәкәте»нең «Алдынгылар советы» дигән үзидарә оешмасы балаларны кече яшьтән үк үз фикерләреңне ишеттерергә һәм башкаларны да ишетергә өйрәтә. Әлеге оешманың үзенчәлекләре нидә?

Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте»нең төбәк җитәкчесе Тимур Сөләйманов алдан ук кисәтә: «Алдынгылар советы»на сайлау җитди һәм чын сәяси сайлаулардан әллә ни аерылмаячак. Монда да дебат оештыру, үз программаңны тәкъдим итү, башкалар белән уртак тел табу, тавыш бирүчеләрнең ышанычын яулау, тавыш бирү нәтиҗәсе белән килешмәгән очракта, апелляция бирү каралган. Кыскасы, барысы да зурлача! Тавыш бирүчеләрне татлы кәнфит белән җәлеп итү дә тыела хәтта! Бары тик идеяләр, тәкъдимнәр генә карала.

Беренчел бүлекчәләр (мәгариф учреждениеләре, яшьләр үзәкләре, өстәмә белем бирү үзәкләре һ.б.) дәрәҗәсендә «совет»лар оеша башлаган инде. Хәзер алар Татарстанның 42 көллияте һәм 929 мәктәбендә бар. Республика күләмендәгесен берничә этапта туплаячаклар.

Тимур Сөләйманов аңлатканча, бу оешмага кергән балалар үзләренең идея һәм тәкъдимнәрен алга сөрә ала. Баштарак – укыган җирләре кысасында булса, соңрак – югарырак урыннарда.

– Алар мәктәпнең таянычына әвереләчәк. Үзләре үк фестиваль, бәйге, төрле чаралар оештырачак. Бу балалар үз ишләренең мәнфәгатьләрен тәкъдим итәчәк, – диде Тимур Сөләйманов.

vk.com

Аның сүзләренчә, бу хәрәкәт мәктәпләрдә була торган гадәти үзидарә оешмаларыннан аерылып торачак.

– Шуны аңларга кирәк: бу, бик зур булса да, әле бик яшь оешма. Кайбер мәктәпләрдә мәктәп укучылары үзидарәләре бик көчле. Кайдадыр алар формаль рәвештә генә бар. Яңа оешма бу эшчәнлеккә яңа энергия, көч өстәячәк дип уйлыйм, – ди Тимур Сөләйманов. – Бу – яңа күренеш, яңа тирәлек. Әлеге балалар үзидарәсе мәктәп кысасында гына калмас. Әлеге оешманың нәтиҗәсен без берничә елдан соң күрәчәкбез.

Кайбер мәктәпләрдә бу советларның лидерлары бар икән инде. Мәсәлән, Казаның 192 нче гимназиясе укучысы Сабина Сабирова үз программасында мәктәп советын булдырырга, мәктәптә «Ел нәтиҗәләре»н үткәрергә тәкъдим иткән. 110 нчы лицейдан Артем Горностаев матбугат үзәкләре оештырырга, Россиянең истәлекле даталарына багышланган көннәргә махсус чаралар үткәрергә кирәк дигән фикердә. Хәзер аларга тырышып эшлисе, сайлаучыларының өметләрен аклыйсы гына кала.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Сыра фетнәсе һәм көтү психологиясе

Ноябрь башы истәлекле даталарга бай. Халыклар бердәмлеге көне белән Татарстан Конституциясе көненнән тыш, социалистик стройны хуп күргән кешеләр Октябрь революциясенең 106 еллыгын да билгеләп үтте. Айның 9 числосы фашизмга, расизмга һәм антисемитизмга каршы халыкара көрәш көне санала. Фашизм димәктән, әле тагын нәкъ менә ноябрьнең 8ендә, Германиядә соңыннан Сыра фетнәсе дип аталып киткән, Гитлер дигән иблисне популярлаштырган, дөньяга чыгарган путч яралуга да төгәл 100 ел тулды…

Дөньяда игелекле гамәлләр белән дан казану авыр. Ә менә начарлык халык күңеленә ныграк уелып кына калмый, тарихи елъязмаларда да аның ишегә урын күбрәк бирелә. Олы гаделсезлек, әлбәттә. Тыныч тормышны өстен күргән, илен, халкын күтәргән патшалар тарих дәреслекләренә керми калырга да мөмкин. Ә сугышканнар, яулап алучылар анда бихисап. Тарихта калу ниятеннән мәшһүр храмны яндырган явыз зат хакында «Геростратны онытыргамы?» дип аталган язмада сөйләгән идек инде. Булачак фюрер да алда искәртелгән затсыз кагыйдәне, ихтимал, белгәндер. Ул да бит – ут төртүче, планетаны Икенче бөтендөнья сугышына кертеп җибәрүче төп явыз. Ә исем, популярлык, дан дигәндә, хәтта сыраханәдә дә, бик теләгәндә, абруй казанырга мөмкин икән. Ул гынамы, шунда ук дәүләт түнтәрелешенә тартым фетнә оештырырга да була икән.

Күз алдына китерик: 1923 ел, ноябрь, ул елларны Веймар республикасы дип аталган Германия, илнең көньяк өлкәсе саналган Бавария, аның башкаласы Мюнхен һәм шәһәрнең зурдан да зур сыра залы – «Бюргербраукеллер» (алманда сыраның үтә дә популяр эчемлек икәнлеген аңлатып тору кирәкмидер). Шунда чыгыш ясаячак Бавария хөкүмәте җитәкчесен тыңларга дип, бирегә өч меңгә якын кеше җыела – сырага мөкиббәннәр һәм бик үк мөкиббән булмаганнар. Тынычсыз, гаугалы вакыт: Рур дип аталган җирләрнең французларга бирелүе аркасында, Баварияның Берлин белән мөнәсәбәтләре начараеп киткән көннәрдә, халык провинция җитәкчесе авызыннан хикмәтле сүз көтә, өлкә, ил язмышларын белергә тели. Ә Гитлерның, ул җитәкләгән партиянең, аның штурмовикларының үз планнары: буталчык вакыттан файдаланып, Бавария армиясен, полицияне үз ягына аудару да Берлинга поход оештыру. Ягъни Италиядә Муссолини ил дилбегәсен ни рәвешле үз кулына алган булса, шул сценарийны Германиядә дә кабатлау. Әмма Гитлер хөкүмәт җитәкчесен, залны вакытлыча үз ягына аудара алса да, армия белән полиция аңа буйсынудан баш тарта. Путч барып чыкмый, булачак баш нацист кулга алына…

Гитлер властька яңадан 10 ел үткәч кенә килә. Тик 1923 елның ноябреннән соң аны инде онытмыйлар. Газеталар, теттереп, аның турында, путч хакында яза. Фетнә, фетнә бастырылганнан соң бер айга якын бара суд процессы, элекке ефрейторның андагы чыгышлары бөтен Германия җәмәгатьчелегенә барып ирешә, ул гынамы, халыкның хәтсез өлешендә яклау да таба. Әлегә гавам явызның олы, моңарчы хәтта затлы саналган халыкны кая илтеп җиткерәсен бөтенләй аңламый. Булачак фюрерга аңлау, әлбәттә, кирәкми. Иярү, халыкның идеология белән исерүе кирәк. Нәкъ шул айларда баш нацистка пиар, русча «раскрутка» дип аталган танылу, реклама эшләнеп кенә калмый, немец кешесенең аңына фашизм оеткысы да шәпләп салына.

Гитлерның биографиясе, аның властька килү тарихы, гомумән дә, халыкны миңгерәүләтүнең җиңеллеген, халык массаларындагы гомуми томаналыкны, аның алдавыч шигарьләргә, бөеклек, өстенлек дигән мифка тиз ышануын бик тә яхшы дәлилли. Халык кимсетелгән, күпмедер фәкыйрь булган тәкъдирдә процесс әле шактый тизәя дә…

Социаль психологиядә «психология толпы» дигән бүлек барлыгы билгеле. «Толпа» дигәндә мәйданга җыелган зур төркемне генә күз алдына китерергә кирәкмидер. «Толпа» ул – гражданлык җәмгыятенең исе дә, төсе дә булмаган аңсыз, кыйбласыз гавам, теге яки бу тарафларда яшәүче сәяси әзерлексез халык. Без сөйләгән очрак өчен «халык» билгеләмәсе дә бик үк туры килеп бетмидер, чөнки ул да билгеле бер оешканлыкны, аңны аңлата. «Население» – «яшәүчеләр» кәлимәсе аңсызлыкны төгәлрәк билгели булыр. Сәясәтчеләр тиз миңгерәүләтә алган гавамны «көтү» дип атауда да хилафлык юк. Ә гражданлык җәмгыятендә яшәгән, дәүләт институтлары аша ил белән идарә итүдә катнашкан халык башка. Ул аңсыз була алмый, гомуми психозга бирешми. Гражданлык җәмгыяте – үз чиратында, илне, дәүләтне, гражданнарны төрле тетрәнүләрдән, фаҗигадән саклаучы иммунитет та. Ә «толпа» гомуми психозга бирешә генә түгел, төрле «коткаручы» идеологияләрне кайчакларда көтеп тә ала.

Беренче бөтендөнья сугышы мескен, бичара хәлдә калдырган, кыйбласыз иткән алман халкы да алда әйтелгән «толпа», көтүче килүен көткән көтү хәлендә булган дисәк, артык ялгышмабыз. Шунысын да билгелик: аерым зат әле мантыйкый һәм тәнкыйди фикерләргә, хәтта дөрес нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Ә идеология белән исертелгән «көтү»дә күбрәк хис-кичерешләр өстенлек итә, кыргый инстинктлар, вәхшәт уяна, аңа критик аң хас түгел. Гитлер төзегән Өченче рейх 1939–1945 елларда кылганнар – хәрабәләр эчендә яткан Европа, дистә миллионнар белән исәпләнгән корбаннар – әйтелгәннең ачык чагылышы…

Сугышлардан котылу бармы? Булса, гражданлык җәмгыятеннән тыш, аңа тагын нинди юллар илтә? Бу сорауга җавапны психоанализ атасы саналган Зигмунд Фрейд белән атаклы физик Альберт Эйнштейн бирә кебек. Аларның Икенче бөтендөнья сугышы башланганчы язышкан хатлары. Кыргый инстинктлардан, күмәк психоздан котылу өчен, адәми зат югары мәдәнияткә ия булырга тиеш, ди алар. Пацифизм – сугышны кўралмауны бары югары культура гына тудыра ала. Бары шуңа ирешкәндә генә кешене кеше дип атап булачак.

ТАТАРСТАН БАЙЛЫГЫ

Бердәмлектә көч

Рухи кыйммәтләрне саклау, халыклар бердәмлеген ныгыту, милли традицияләрне торгызу. «Казан Экспо»да Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы белән саубуллаштылар. Чара Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан узды. Иртәдән кичкә кадәр узган бәйрәмдә «ВТ» хәбәрчесе дә булып кайтты.

tatarstan.ru

Иртәнге сәгать 10. Бу вакытта «Казан Экспо» тирәсендә халык әллә ни күренми иде әле. Иркенләп йөри торганда, 11 тулып киткәч кенә, җыела башладылар. Нинди генә милләт вәкиле юк иде монда бу көнне!

Татарстанда гомер итүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасы бик зур һәм бай. Бәйрәм көнне бу байлык «Казан Экспо»ны да чолгап алган иде. Күргәзмәгә куелган әйберләр милләтләрнең тарихын, мәдәниятен, телен, әдәбиятын, этнографиясен, гореф-гадәтләрен чагылдырган.

Быел узган күп чараларга хас булганча, биредә республикада яшәүче халыкларның милли ишегаллары да оештырылган. Аларга кергәч, үзеңне кунакка баргандай хис итәсең. Һәрберсе елмаеп каршы ала. Керәшеннәрнең Питрау, чуашларның Уяв, мариларның Семык, русларның Каравон, удмуртларның Гырон быдтоны – барысы да бар. Ни өчендер Сабан туе гына юк иде. Дөрес, төрки халыкларның Нәүрүз бәйрәме тәкъдим ителгән. Тик безнең милләтнең иң яраткан бәйрәме булмау сәер дә, кызганыч та. Гомумән, татарларга бу көнне игътибар азрак бирелгән кебек тоелды.

Күргәзмәләр буйлап…

Әлки районы Базарлы Матак авылы мәдәният йорты режиссеры Эльмира Шиһапова «Пилеш» чуаш музыкаль-фольклор коллективына йөри. Күргәзмәләр буйлап йөргәндә, җәһәт кенә аның белән аралашып алдык:

– Ансамблебез егерме елдан артык эшләп килә. Коллективта миннән кала бөтенесе – чуаш. Без бүген «Уяв» күренешен күрсәтәбез. Уяв бәйрәме хәзер ел саен Әлки районында үткәрелә. Чуаш халкының үзләренә генә хас булган гореф-гадәтләре, йолалары бар. Без аларның бөтенесен искә алып, бәйрәмнәрдә чыгыш ясыйбыз. Күргәзмәгә кул эшләре, баш киемнәре, милли курчаклар, чигүле эшләр, борынгы көнкүреш кирәк-ярагын алып килдек. Мондый бәйрәмнәр бар халыкны – татарын да, русын да, чуашын да берләштерә, дуслаштыра. Без гомергә бердәм эшләдек, яшәдек. Менә бит әле, татар булуыма карамастан, чуашлар белән чуашча җырлап йөрим. Бердәм булырга кирәк. Элек ничек бергә дус-тату яшәдек, алга таба да шулай яшәргә иде.

Мамадыш районының Колышчы авылыннан Валентина Максимова ун елдан артык лаеклы ялда. Хәзер ул тәңкәләрдән тамакса (керәшеннәрнең муенга тага торган бизәнү әйбере) ясау белән шөгыльләнә.

– Ике ансамбль килдек: безнең Колышчы авылының «Покрау» фольклор ансамбле һәм Дусмәт авылыннан «Тәңкәләр» балалар фольклор ансамбле. Мамадыш районы 25 ел рәттән бөтен дөньяга билгеле булган Питрау бәйрәмен уздыра. Бүген без монда Питрау чибәренең өе сымак иттереп, бер почмак эшләп, өстәл көйләп куйдык. Тамаксалар ясау буенча кызыксынган кешеләргә осталык дәресе дә үткәрәм. Керәшеннәрнең тәңкәләрдән эшләнмәләре бик күп. Аны бизәнү әйбере диләр, әмма алай дөрес түгел, чөнки бездә ул күбрәк саклаучы ролен үти. Борын-борыннан шулай булган һәм хәзер дә бар. Аларны заманчалаштырып та, элеккечә дә эшлибез.

«Тарихыбызны белеп бетермибез»

Беренче катта күргәзмәләр, бәйрәм гөрләгәндә, икенче катта халык белем бирү семинарларында катнашты, диктант язды. «Зур этнографик диктант» VIII бөтенроссия акциясендә теләгән һәркем катнаша алды. Диктант биреме 30 сораудан тора, аны язу өчен катнашучыларга 45 минут вакыт бирелгән иде. Диктант Россиядә яшәүче халыклар турындагы белемнәрне тикшерергә мөмкинлек бирә.

– «Этнографик диктант»ны ел да язам. Бик кызык. Беренче карашка катлаулы, чөнки Россия территориясендә яшәүче милләтләрнең көнкүреше, гореф-гадәте, мәдәниятенә бәйле. Ләкин уйласаң, ерып чыгарга була, – ди диктантта катнашучы Мөслим районы Иҗтимагый советы рәисе Рушат Солтанов. – Без күпмилләтле республикада яшибез. Үзебезнең Мөслим районында гына да егермедән артык милләт вәкиле бар. Бер-беребезнең мәдәниятен белү бер-беребезгә карата хөрмәтне арттыра, якынайта. Күпмилләтле дәүләт булারак, без, һичшиксез, дус-тату яшәргә бурычлы. Шул вакытта гына илебез көчле, тормышыбыз ямьле. Без бер-беребезнең тормышын ямьләп яшибез.

Сүз уңаеннан, «Зур этнографик диктант» халыкара акциясе республикада 3–8 ноябрьдә узачак.

Быелгы иң зур проектларның берсе – Татарстанның чигелгән картасы күргәзмәләр үзәгенең беренче катында урнашкан иде. Һәр районның җирле осталары ясаган, милли бизәкләр төшерелгән карта да үз янына күп халыкны җыйды.

«ТАТАРСТАННЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ» РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

Гран-при >>	Арча районы
1 урын >>	Әтнә, Актаныш, Алабуга районнары
2 урын >>	Теләче, Аксубай, Кукмара районнары
3 урын >>	Чүпрәле, Саба, Бөгелмә районнары

«Без бердәм булганда гына көчле»

Бәйрәм Илһам Шакиров исемендәге концерт залында тантаналы концерт белән тәмамланды. Чарада катнашучыларны һәм кунакларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сәламләде.

– Бүгенге бәйрәм – безнең Ватаныбыз халыклары бердәмлеген раслау, уртак җиңүләр һәм казанышлар символы. Без бердәм булганда гына көчле, дус һәм тату яшибез, – диде тантаналы ачылышта Рөстәм Миңнеханов. – «Безнең йорт – Татарстан» этномәдәни фестивале соңгы елларда бөтен республиканы колачлады. Аның нәкъ менә Халыклар бердәмлеге көнендә узуы символик мәгънәгә ия. Бирердә Татарстанның иң яхшы халык коллективлары чыгыш ясый. Чарада катнашучыларның барысына да милли мәдәнияткә мәхәббәте һәм аны популярлаштыруга өлеш кертүләре өчен рәхмәт белдерәсем килә.

Татарстан Рәисе сүзләренә караганда, илгә зур басым ясалган шартларда, Россиягә дус булмаган илләр җәмгыятьне таркатырга һәм кешеләрне милли һәм дини билгеләр буенча аерырга тырышканда, бердәм булу аеруча мөһим.

– Илнең суверенитетын, аның алга таба үсешен саклауның аерылгысыз шарты булып, төрле милләт һәм конфессия вәкилләре арасында тынычлык һәм татулыкны саклау тора. Шул максаттан республикада төрле дәүләт программалары гамәлгә ашырыла, Татарстанда яшәүче халыкларның телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен үстерү өчен шартлар тудырыла, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, быел республика районнарының Мәдәният көннәре уздыру традициясен дә яңарттылар. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елының ябылу тантанасында «Татарстанның мәдәни башкаласы» республика бәйгесе җиңүчеләре билгеле булды. Ел дәвамында бу исем өчен республиканың 45 районы көрәште. Гран-прига һәм «Татарстанның мәдәни башкаласы» исеменә Арча районы лаек булды. Җиңүче районга 3 млн сумлык сертификат бирелде.

Ләйсән САФИНА

Нәтиҗә

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

«Татар-информ»

Үзәктә – гади кешеләрнең тормыш фәлсәфәсе, төрле милләтләр язмышы, ватанпәрвәрлек хисе. «Многоликая Россия» XIV Бөтенроссия журналистлар бәйгесендә җиңүчеләрнең хезмәтләре шул хакта иде. Басма матбугат номинациясендә җиңүчеләр арасында «Ватаным Татарстан» газетасы да бар. Гран-прига Төньяк Осетиянең «Осетия-Ирыстон» милли телекомпаниясе лаек булды.

Быел бәйгегә илнең 38 төбәгеннән 820 эш тәкъдим ителгән. Арада Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Алтай, Байкал аръягы крае, Калининград, Калуга өлкәләре, Адыгея, Башкортстан, Дагыстан, Калмыкия, Саха (Якутия) вәкилләре дә бар. Конкурс алты номинациядә узды. Болар – «Телесюжетлар циклы», «Телепроект (документаль фильм, телепрограммалар циклы)», «Радиотапшырулар циклы (репортажлар)», «Басма матбугатта мәкаләләр циклы», «Интернет-массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар циклы», «Массакүләм мәгълүмат чараларында балалар-үсмерләр мәгърифәтчелек проектлары».

Гран-при откан «Осетия-Ирыстон» милли телекомпаниясе 91 яшьлек ватанпәрвәр укытучы Роальд Каупуш турында фильм төшергән. Әлеге герой үзенең тормыш фәлсәфәсе, кешеләрне яратуы, ватанпәрвәр булуы белән гашыйк итә. Шушы яшьтә укучылары белән походка йөрергә, тауга менәргә каян көч таба диген?

– Героем – латыш милләтеннән. Мин Роальд Каупуш белән походта танышкан идем. Ул бездәге барлык тауларга менгән. Аның турында фильмны бер ел буе төшердем, – дип сөйләде тележурналист Ольга Абаева газета хәбәрчесенә. – Танылган шәхес түгел. Бик тыйнак кеше ул. Аны 62 ел элек Төньяк Осетиягә урманчы итеп эшкә җибәргәннәр. Алагир авыл хуҗалыгы техникумына нигез салган. Әле дә шунда студентларга белем бирә. Балаларны үз иленең патриоты булырга өйрәтә. 90 яшьтә чаңгыга баскан. Үзе генә яши. Тверь өлкәсендә яшәүче кызына кунакка баргач, сазлыктан мүк җиләге җыя. Шуннан морс ясап, кыш буе эчә. Сәламәтлек өчен файдалы, ди. Бабай социаль челтәрләрдә дә актив.

Гран-прины Ольга Абаевага Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды. Җиңүче 500 мең сумлык төп призның милли телеканал үсешенә тотылачагын әйтте.

Фәрит Мөхәммәтшин бәйгене уздыру идеясенең күпмилләтле Татарстанда туып, шунда тормышка ашырылуын һәм елдан-ел популярлаша баруын әйтте. «Безнең өчен бу – зур җаваплылык. Әлеге конкурсның мөһимлеген һәм ихтыяҗын аңлыйбыз, бигрәк тә хәзерге вазгыятьтә», – диде парламент башлыгы.

Фәрит Мөхәммәтшин, милләтләр дуслыгына басым ясап, республикада 175 милләт вәкиле яшәвен, аларның үз туган телләрендә сөйләшүен, мәдәният, гореф-гадәтләрне саклау мәсьәләләренең актуальлеген югалтмавын әйтте. «Бу – безнең мәңгелек кыйммәтләребез», – диде.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев әлеге чараны вазгыятьне тагын бер тапкыр анализлау, милли темага ихтыяҗ булуын аңлау өчен мөмкинлек дип бәяләде.

Тантанада Россия Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисе Геннадий Семигин, Россия Федерациясе сенаторы Александр Терентьев, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Юрий Никитин, Россия телевидениесе алып баручысы Арина Шарапова да катнашты.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе «Басма матбугатта мәкаләләр циклы» номинациясендә өченче урын алды. Күзәтеп барган булсагыз, газетада «Мин – милләт», «Милли аккорд», «Үз илемдә – үз телем» проектлары алып барыла. Без төрле милләт вәкилләренең ничек итеп мәдәният, тел, гореф-гадәтләрен саклаулары турында даими рәвештә язабыз, өйрәнәбез.

Бәйгедә берничә ел рәттән катнашучылар да бар. Дагыстаннан килгән тележурналист Патимат Бурзиева шундыйлардан.

– Сюжетларымда беткән авылларда яшәүче гади кешеләрне яктыртырга тырышам. Бездә агач йортлар юк, барысы да – таштан. Юлсызлык, сусызлык, җир аз булу. Яшәү шартлары булмау сәбәпле, авыллар юкка чыккан, – ди Патимат. – Бу юлы Харбук авылында яшәүче даргин милләтеннән булган 60 яшьтән узган Җәүһәр ханым турында фильм эшләдем. Ул – тимерче, әби-бабайлары һөнәрен әле дәвам иттерә, оныкларына өйрәтә. Бүләккә кылычлар ясый. Көчле рухлы кешеләр – тормышның бер бизәге бит алар.

Киләсе елга икенче бер кечкенә авылда яшәп, җомга көнне бушлай ипи пешереп таратучылар турында фильм әзерләргә җыена. Журналистлар быелдан ук бәйгегә җим туплый башлаган инде.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН БЮДЖЕТЫ: БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШ

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ «2024 ЕЛГА, 2025 ҺӘМ 2026 ЕЛЛАР ПЛАН ЧОРЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ ТУРЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ ПРОЕКТЫН БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШТА КАБУЛ ИТТЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ – ИКЪТИСАД МИНИСТРЫ МИДХӘТ ШАҺИӘХМӘТОВ ЧЫГЫШЫ

Сезнең игътибарыгызга ике мең дә егерме дүрт һәм ике мең дә егерме алтынчы елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы кертелә. Фараз параметрлары парламент тыңлауларында һәм Дәүләт Советы комитетларында җентекләп тикшерелде.

Фараз агымдагы вазгыятьне, илнең һәм республиканың икътисадый үсешенең тышкы һәм эчке факторларын бәяләп, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Рәисе билгеләгән бурычларны исәпкә алып төзелде.

Чикләүләр һәм санкцияләр басымына карамастан, республика предприятиеләре һәм оешмалары күп кенә чакыруларны читләтеп, инвестиция активлыгын һәм җитештерүләрне саклап кала алды.

Республиканың оператив штабы, шул исәптән депутатлар катнашында, социаль-икътисадый тотрыклылыкны һәм икътисадны үстерүне тәэмин итү, ярдәм чараларында катнаштыру буенча предприятиеләр белән килештерелгән эш оештырды.

Агымдагы елда республиканың система булдыручы оешмалары 45 млрд сум күләмендә федераль ярдәм чараларын алды.

Кече һәм урта бизнес предприятиеләренә инде 57 млрд сумлык ярдәм күрсәтелде.

Икътисадның база тармаклары предприятиеләре һәм оешмалары, гамәлгә ашырыла торган инвестицион проектлар, федераль һәм республика ярдәм чаралары фаразларын исәпкә алып, 2023 ел йомгаклары буенча республиканың тулай төбәк продукты 3,9 трлн сум дәрәҗәсендә бәяләнә.

Республиканың икътисадый үсешенә төп өлеш кертүчеләр:

– сәнәгать, беренче чиратта эшкәртү производстволары;

– юл төзелешен исәпкә алып, төзелеш секторы;

– сәүдә, азык-төлек булмаган товарлар төркеме әйләнешен торгызу хисабына.

Хәзерге шартларда республиканың 2024–2026 елларга социаль-икътисадый үсешенең фаразланган күрсәткечләре әлеге предприятиеләр һәм оешмалар, тармак министрлыклары, муниципаль берәмлекләрнең үсеш фаразларын, шулай ук илкүләм проектларны, дәүләт программаларын һәм гражданнарның тотрыклы үсеше һәм иминлеге өчен ярдәм итү чаралары комплексын гамәлгә ашыру күрсәткечләрен исәпкә алып формалаштырылды.

Тулай төбәк продукты 2024 елда аннан алдагы елга карата чагыштырма бәяләрдә 102,2% дәрәҗәсендә фаразлана.

Үсеш нигезендә – илебез җитештергән товарларга һәм хезмәтләргә ихтыяҗның артуы һәм республика предприятиеләренең тәкъдимнәр формалаштыруда катнашуын тәэмин итү.

Республика икътисады структурасында иң зур өлешне сәнәгать алып тора.

Предприятиеләр планнарын гамәлгә ашыруны исәпкә алып, сәнәгать җитештерүе индексы 2024 елда 102,5% дәрәҗәсендә фаразлана.

Фараз күрсәткечләрен үтәүнең мөһим факторлары булып инвестиция проектларын гамәлгә ашыру һәм предприятиеләрнең өзлексез һәм нәтиҗәле эшен тәэмин итү тора.

Барлык күрсәтелгән юнәлешләр буенча дәүләттән ярдәм чаралары бар. Алар буенча мәгълүмат республика Икътисад министрлыгы сайтында урнаштырылган.

Предприятиеләргә ярдәм чаралары турында мәгълүмат бирүне һәм аларга һәр заявка буенча булышлык күрсәтүне дәвам итәргә кирәк.

Баланс комиссияләре эше кысасында предприятиенең фараз күрсәткечләренә ирешмәү куркынычы булганда, предприятиеләр хуҗалары белән берлектә тиешле карарларны оператив рәвештә хәл итәргә кирәк.

Конкрет тармакларның һәм предприятиеләрнең хәзерге торышын гына түгел, ә тышкы шартларның үзгәрүен дә игътибар белән күзәтү, мөмкин булган куркынычларга оператив рәвештә җавап бирү, аларны вакытында бетерү мөһим.

Шул ук вакытта республиканың сәнәгать җитештерүен үстерү өчен стратегик яктан түбәндәгеләр мөһим:

– Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше программасы чараларын нәтиҗәле тормышка ашыруны тәэмин итү;

– шулай ук җитештерелгән продукция күләменең 60 проценты формалашкан нефть-газ химиясе комплексының әһәмиятен исәпкә алып, 2030 елга кадәр тармакны үстерүнең яңа программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру.

2024 елда, агымдагы елның түбән базасын исәпкә алып, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, фараз буенча, агымдагы ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 110,7% тәшкил итәчәк, шул исәптән үсемлекчелектә – 121,9%, терлекчелектә – 101,5%.

2025–2026 елларда тармак дәүләт программасы нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясенең үсеш темплары 101,9% дәрәҗәсендә каралган.

Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фараз күрсәткечләренең үтәлешен тәэмин итү факторлары слайдта күрсәтелгән.

– Планлаштырыла торган срокларда инвестиция проектларын гамәлгә ашыру һәм гамәлгә кертү, шул исәптән җитештерелә торган продукцияне эшкәртү күләмнәрен арттыру.

– Импортны алмаштыру программаларын, шул исәптән орлыкларны, утырту материалын, терлекчелекнең токымлы продукциясен гамәлгә ашыру.

– Авыл хуҗалыгы оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен технологияләр кертү буенча хуҗалыкларның иң яхшы тәҗрибәсен җәелдерү.

– Шулай ук авылда хуҗалык итүнең кече формаларын алга таба үстерү.

Халыкның ихтыяҗларын тәэмин итүнең төп сегментларының берсе – кулланучылар базары.

Кулланучылар активлыгын торгызу һәм базарны яңадан ориентацияләү дәвам итә.

Азык-төлек булмаган сегментта үсеш беренче чиратта җиңел автомобильләр сатуны торгызу хисабына тәэмин ителә.

2024 елга ваклап сату әйләнеше 102,5% дәрәҗәсендә фаразлана.

Тышкы сәүдә дә үзгәртеп корыла. Дустанә илләр белән хезмәттәшлекне тирәнәйтү тренды ачык билгеләнде. Агымдагы елда алар белән товар әйләнеше артты.

Шулай ук маркетплейсларда теркәлгән тәэмин итүчеләр санын арттыру тенденциясе дә дәвам итә.

Быел үз товарларын маркетплейсларда сатучы Татарстан халкы 23 процентка артып, 56 мең сатучыга җиткән.

Республиканың җәмәгать тукланулы әйләнеше 103,5–104,0% дәрәҗәсендә фаразлана, шул исәптән туризмның алга таба үсеше нәтиҗәсендә дә.

Туристлык тармагын үстерү максатларында федераль дәрәҗәдә махсус ярдәм чаралары кабул ителде:

– салым преференцияләре;

– шулай ук тиешле илкүләм проект кысаларында чаралар һәм башка ярдәм чаралары.

Әлеге ярдәм чараларын туристлык өлкәсен алга таба үстерү һәм республикага туристларны җәлеп итү өчен максималь файдаланырга кирәк.

Республиканың төзелеш комплексында торак, сәнәгать һәм инфраструктура төзелеше күләмнәрен саклау каралган.

Торак төзелешендә фараз 2024–2026 елларда 9 млн кв. метрдан артык торакны файдалануга тапшыруны күздә тота.

Төзелеш секторында фараз үтәлешен тәэмин итү факторлары слайдта күрсәтелгән.

– Пространстволы планлаштыру институты тарафыннан эшләнә торган территорияләрне үстерү буенча комплекслы алымны гамәлгә ашыру.

– Инфраструктураны алгарышлы үстерүне тәэмин итү.

– Инвестиция-төзелеш циклын кыскарту һәм капиталь төзелеш объектларын билгеләнгән срокларда файдалануга кертү.

– Төзелеш материаллары, җиһазлар һәм комплектлаучы материаллар буенча импортны алмаштыру.

Хөрмәтле депутатлар!

Инвестиция проектларын гамәлгә ашыру социаль-икътисадый үсеш фаразын тәэмин итүнең төп факторларының берсе булып тора.

Безнең бәяләмә буенча, агымдагы елның 9 аенда төп капиталга инвестицияләр күләме 750 млрд сум тәшкил иткән.

Агымдагы шартларда инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен даими нигездә инвестиция климатын яхшырту буенча нәтиҗәле эшне дәвам итәргә кирәк.

Булган резервлар буенча чаралар эшләү өчен «Росатом» дәүләт корпорациясе белән берлектә инвестор эшчәнлегенең 9 алгоритмы кысасында «Үтәли инвестиция агымы» проектын гамәлгә ашыру буенча эш алып барылды. Һәр юнәлеш буенча тиешле юл карталары әзерләнгән.

Җаваплы министрлыкларга, ведомстволарга, ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларга һәм муниципаль берәмлекләргә аларның сыйфатлы үтәлешен тәэмин итәргә кирәк.

Инвестиция эшчәнлеген стимуллаштыру максатыннан инвесторлар өчен шартларның тотрыклылыгы, инвестиция проектлары өчен инфраструктура, капиталның һәм заем финансларының булуы, дәүләт, инвесторлар һәм финанс секторы арасында куркынычларны грамоталы бүлү мөһим.

Технологик яктан катлаулы проектларга инвестицияләр кертүне хуплау – аерым өстенлек.

Моның өчен дәүләт ярдәме чараларының киң инструментарие эшли.

Предприятиеләр белән берлектә аларны максималь файдалану мөмкинлеген эшләргә кирәк.

Махсус икътисадый зоналарда һәм алгарышлы үсеш территорияләрендә зур потенциал саклана.

«Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисадый зоналары күрсәткечләре буенча мәгълүмат слайдта күрсәтелгән.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасында 57 резидент урнашкан.

Резидентлар тарафыннан башкарылган инвестицияләр күләме бөтен чорда 163,9 млрд сумнан артып китә, 8 мең 880 эш урыны булдырылган.

«Иннополис» махсус икътисадый зонасында 342 компания эшли, шул исәптән 125 резидент, 59 партнер-компания һәм 158 стартап бар.

Эшчәнлек башланганнан бирле 7 мең 999 эш урыны булдырылган, 112,2 млрд сум инвестицияләнгән.

Агымдагы елда Россия Федерациясе Хөкүмәте инвесторлар файдалана алырлык икътисадый эшчәнлек төрләре исемлеген киңәйтте.

Моношәһәрләргә өстәмә резидентлар җәлеп итү мөмкинлекләреннән файдаланырга кирәк.

Күрсәтелгән моношәһәрләр башлыкларына Россия Икътисадый үсеш министрлыгы белән килешүләр кысасында алынган йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итәргә кирәк.

Ислам илләреннән чит ил инвесторларын җәлеп итү өчен Россия Федерациясенең аерым субъектларында партнерлык финанслары эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатында махсус көйләү билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында 2023 елның 4 августындагы 417-ФЗ номерлы федераль законны гамәлгә ашыру мөһим юнәлеш булып тора.

Финанс базарының әлеге сегментын максатчан үстерү аның системалылыгын һәм көйләү сыйфатын арттыруны, шулай ук партнерлык һәм традицион финансларны гамәлгә ашыру шартларын тигезләүне таләп итә.

Экспериментның төп максатлары булып проблемаларны ачыклау һәм булган хокукый киртәләрне бетерү, уңай хокукый шартлар булдыру өчен норматив җайга салуның оптималь механизмын эшләү тора. Бу халык һәм бизнес өчен партнерлык финанслары коралларының мөмкинлеген арттыруга һәм үстерүгә, шулай ук инвестицияләүнең әхлакый һәм дини аспектларына игътибарны арттыручы халыкара инвесторларны җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Әлеге бурычны нәтиҗәле тормышка ашыру өчен банк секторы, югары уку йортлары, руханилар, экспертлар берләшмәсе, базарда катнашучылар, республика министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә, Татарстан Республикасында эксперимент чорына партнерлык финансларын үстерү буенча чараларның җентекле планы (юл картасы) төзелде.

Хөрмәтле депутатлар!

Республикабызның социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү өчен кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөһим роль бирелә.

Гомумән, кече һәм урта эшкуарлык секторында уңай динамика күзәтелә, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны 3,8 процентка артты.

Агымдагы ел ахырына кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны 170 мең берәмлек дәрәҗәсендә бәяләнә.

Фараз буенча 2024 елга кече һәм урта эшкуарлык саны 175 меңнән артачак.

Кече һәм урта бизнеста эшләүчеләр саны, үзмәшгульләрне исәпкә алмаганда, 2023 ел йомгаклары буенча 600 меңнән артып китәчәк.

Хөрмәтле депутатлар!

2030 елга кадәр кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

– хезмәт нәтиҗәлелеген һәм җитештерүчәнлеген арттыру;

– кече һәм урта эшкуарлык оештыру шартларын яхшырту;

– аларның гомер озынлыгын арттыру;

– кече һәм урта эшкуарлык структурасын диверсификацияләү.

Күрсәтелгән бурычларны тормышка ашыру буенча төп юнәлешләр слайдта күрсәтелгән.

– Яңа гына эшли башлаган кече һәм урта эшкуарлык өчен финанс ярдәм чараларын (микрозаемнар, грантлар, поручительлекләр) яраклаштыру.

– Салым буенча ярдәм чараларын куллануны киңәйтү (салым салуның гадиләштерелгән автомат системасын киңәйтү һәм аерым тармаклардан булган эшкуарларны өстәмә хак салымыннан азат итү).

– МСП.РФ платформасында ярдәм чараларын цифрлаштыру.

– Кече һәм урта эшкуарлык секторында экспорт потенциалын гамәлгә ашыру.

– Сәнәгать паркларын, технопаркларны үстерү.

– Эре һәм кече бизнес кооперациясен төзү.

– Кече һәм урта эшкуарлыкның инвестиция эшчәнлеген стимуллаштыру.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе нигезендә 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юллама кысасында бизнес-берләшмәләр белән берлектә республикада эшкуарлык климатын яхшырту буенча чаралар планы формалаштырыла.

Әлеге планга эшкуарлардан кире элемтәне исәпкә алып, күрсәтелгән бурычларны һәм кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә дәүләт сәясәте юнәлешләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар кертеләчәк.

Кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә фаразлау күрсәткечләрен тәэмин итү өчен төп резерв булып муниципаль сәнәгать паркларын үстерү тора, сәнәгать паркларының уртача йөкләнеш дәрәҗәсе ел башыннан 10 процентка артты һәм 63 процентка җитте.

Моңа республика ярдәм итү механизмнарын, салым преференцияләрен куллануны исәпкә алып, сәнәгать паркларын үстерү концепциясе ярдәм итә. Быел «Түбән Кама», «Промзона-Минзәлә», «Алексеевск», «Арча» сәнәгать паркларында инфраструктура чикләүләрен бетерү буенча эш алып барылды.

Фараз чорында сәнәгать паркларының инженерлык инфраструктурасын үстерүгә һәм модернизацияләүгә юнәлдерелгән ярдәм чараларын гамәлгә ашыру дәвам итәчәк.

Муниципалитетларның һәм бизнес-берләшмәләрнең бурычы:

– эшкуарларны федераль һәм республика ярдәм чараларына максималь җәлеп итү максатыннан, адреслы эшне дәвам итү, эшкуарлык климатын яхшыртуда ярдәм итү.

Җитештерелгән продукциягә ихтыяҗ булдыру һәм эре һәм кече бизнесның үзара эшчәнлеген төзү инструментларының берсе булып биржа мәйданчыгы – Республика маркетинг үзәге тора.

Агымдагы елның 10 ае йомгаклары буенча 4 меңләп субъект ресурс ярдәмендә 123,1 млрд сум күләмендә керем алган.

Кече һәм урта эшкуарлык үсешенә үзмәшгульләр институтына зур өлеш кертә. Күпчелек өчен эшкуарлык эшчәнлеген башлауда бу – беренче адым.

Бурыч:

– үзмәшгульләрне Кече һәм урта эшкуарлык илкүләм проекты кысасында гамәлгә ашырыла торган ярдәм чараларына максималь җәлеп итүне тәэмин итәргә.

– икътисадый актив үзмәшгульләр өлешен арттыру максатыннан, «Минем салым» кушымтасында үз эшчәнлекләрен чагылдыру буенча адреслы эш алып барырга.

Бүген республикада үзмәшгульләрнең 56 проценты яки 150 мең кеше генә икътисадый яктан актив.

Игътибар итегез: үзмәшгульләр үз эшчәнлекләрен «Минем салым» кушымтасында чагылдырганда гына ярдәм чараларыннан файдалана ала;

– моннан тыш, республика шәһәрләрендә һәм районнарында үзмәшгульләр өчен махсус ярминкәләр үткәрүне дәвам итәргә кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Барлык комитетларда депутатлар тарафыннан билгеләп үтелгән социаль-икътисадый үсеш фаразын тәэмин итүнең иң мөһим факторы булып кадрлар белән тәэмин ителеш тора. Үсә барган икътисадка күбрәк белгечләр кирәк.

Хәзерге вакытта республика эш бирүчеләре тарафыннан 47 меңнән артык вакансия тәкъдим ителә.

Шул ук вакытта республикада хезмәт базарында быел теркәлгән эшсезлекнең рекордлы түбән дәрәҗәсе күзәтелә.

Республика Хезмәт министрлыгы тарафыннан кадрлар кытлыгын тулыландыру буенча алып барылган эшкә өстәп, шул исәптән:

– эшсез халыкның икътисадый активлыгына этәргеч бирү;

– аерым категория гражданнарны эшкә урнаштырганда предприятиеләрне укыту һәм финанс ярдәме күрсәтү;

– оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә кадрлар җәлеп итү.

Тагын да зуррак әһәмияткә ия булган чаралар:

– хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру программаларын гамәлгә ашыру, шул исәптән яңа технологияләр кертү, автоматлаштыру һәм роботлаштыру;

– республика предприятиеләренә чыгарылыш укучыларын максималь дәрәҗәдә эшкә урнаштыру өчен белем бирү оешмалары белән предприятиеләр кооперациясен арттыру.

Тармак министрлыкларына һәм муниципаль берәмлекләргә предприятиеләр белән берлектә әлеге эшнең иң яхшы практикаларын тиражларга кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Билгеләнгән бурычларны тормышка ашыру халыкның социаль тотрыклылыгын һәм иминлеген тәэмин итү өчен нигез булып тора.

2024 елга реаль хезмәт хакының 102,4% дәрәҗәсендә үсеше планлаштырыла.

Хезмәт хакын арттыру өчен нигез булып хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше тора.

Татарстан Республикасы «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын гамәлгә ашыруда актив катнаша.

2023 елда илкүләм проектта Татарстанның 234 предприятиесе катнаша. Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларына 4 меңнән артык предприятие хезмәткәре өйрәтелгән.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, фаразланган чорда хезмәт җитештерүчәнлегенең реаль хезмәт хакы дәрәҗәсеннән алдарак үсеше каралган.

Республиканың социаль-икътисадый үсешенең куелган максатларына ирешүнең мөһим инструментларының берсе булып илкүләм проектлар чараларын гамәлгә ашыру тора.

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга агымдагы елда федераль һәм республика бюджетларыннан 43,0 млрд сум күләмендә финанслау лимиты каралган.

2023 елның 31 октябренә бүлеп бирелгән акчаларны касса аша үзләштерү күләме 35,5 млрд сум тәшкил итте, ягъни лимитның 83 проценты.

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру бурычлары слайдта тәкъдим ителгән.

– Төзелгән дәүләт контрактлары кысаларында эшләрне вакытында һәм сыйфатлы үтәүне тәэмин итәргә.

– Илкүләм проектлар чараларына бүлеп бирелгән акчаларны тулысынча үзләштерүне тәэмин итәргә.

– Республикабыз халкының тормыш сыйфатын билгеләүче 163 күрсәткечкә ирешүне тәэмин итәргә.

2024 елга кадәр, федераль тармак министрлыклары белән берлектә, федераль бюджеттан финанслау чаралары исемлеген раслау буенча эш алып барырга кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

2024–2026 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлауның төп параметрлары әнә шундый.

Фараз күрсәткечләренә ирешү өчен барлык дәрәҗәдәге хакимият, предприятие һәм оешмалар үзара килешенеп һәм координацияле эшләргә тиеш, килеп туган проблемаларның чишелеш юлларын ачыклау һәм икътисадый үсеш резервларын билгеләү өчен оператив йогынты чараларын күрергә кирәк.

Тиешле эш республиканың тотрыклы икътисадый үсешен тәэмин итү буенча оператив штабның эшче төркеме кысасында дәвам итәчәк.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЫ РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН ЧЫГЫШЫ

Республика Конституциясенең 94 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 маддәсе нигезендә Рәис тарафыннан Дәүләт Советына тикшерүгә киләсе 2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына бюджет турында закон проекты кертелде.

Татарстан Республикасының бюджет турындагы закон проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы тарафыннан куелган таләпләргә туры китереп әзерләнде.

Закон проектын 23 маддә һәм 38 кушымта тәшкил итә. Закон проектында Бюджет кодексы тарафыннан каралган документлар һәм материаллар бар. Аларда бюджет формалаштыру барышын тулысынча чагылдырган мәгълүмат тупланган. Шуларның иң әһәмиятлеләре – социаль-икътисадый үсеш фаразы һәм аның үтәлеше анализы, бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, керемнәр буенча исәп-хисаплар, бюджет үтәлешенең көтелгән бәяләве, бюджетара трансфертларны хисаплау методикалары, дәүләт программалары паспортлары.

Бюджетның керем өлеше өстендә эш турында кыскача. Бюджетның керем өлешен формалаштыру – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «база» варианты һәм республикабыз Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнгән Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырылды.

Бер үк вакытта, фаразда федераль бюджет һәм салым законнарының үзгәрешләре исәпкә алынган.

Республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итү өчен, керемнәр буенча бюджет проектында, гамәлдәге салым ташламалары һәм планлаштырылган чорга аларның кайберләренең озайтылуы исәпкә алынды.

Керемнәр

Алга таба өчьеллык чорга бюджетның төгәл керем чыганаклары турында.

Чыгышымда 2024 елга керем һәм чыгымнар күләмнәрен әйтеп, ә план чорына, ягъни 2025 һәм 2026 елларга күрсәткечләрне экранда күрсәтеп барачакмын.

Табышка салым керемнәрен бәяләгәндә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча «Табыш» күрсәткеченең фаразланган күләме, республиканың эре һәм урта оешмалары мәгълүматлары, салым органнарының хисаплылыгы, шулай ук узган чорда салым кереме динамикасы файдаланылды.

Нәтиҗәдә 24 елда табышка салым кереме фараз буенча 112,8 млрд сум тәшкил итәчәк.

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына физик затлар керемнәренә салым кереме 137,5 млрд сум күләмендә фаразлана. Республика бюджетына керемнәр 96,4 млрд сум тәшкил итәчәк. Салым буенча исәпләүләр Икътисад министрлыгы фаразлаган хезмәт өчен түләү фондыннан, агымдагы елда салым керемнәре суммасыннан һәм планлаштырылган чорда аның үсеш темпларыннан чыгып башкарылды.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына акцизлар кереме фаразы 43,0 млрд сум тәшкил итә.

Киләсе салым – оешмалар мөлкәтенә салым. 2024 елда ул 39,1 млрд сум күләмендә фаразлана. Аны планлаштырганда – төп капиталга инвестицияләр фаразы, салым хисабы мәгълүматлары исәпкә алынды.

Муниципаль берәмлекләр бюджетларының шактый зур керем чыганагы – җир салымы. Салым буенча фараз салым хисабы нигезендә исәпләнде һәм барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары белән килештерелде. Аның керемнәре ел саен бертөрле, 8,4 млрд сум күләмендә фаразлана.

2024 елда транспорт салымының керемнәре 6,9 млрд сум күләмендә бәяләнә. Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә транспорт салымы юл фондына фаразланган күләмнәрдә җибәреләчәк.

Җыелма керемгә салымнар буенча керем Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына 25,6 млрд сум күләмендә фаразлана. Фараз, хисаплылыктан һәм алынган керемнәр динамикасыннан чыгып формалаштырылды.

Тулысынча муниципаль берәмлекләр бюджетларына күчерелә торган физик затлар мөлкәтенә салым 2024 елда 2,7 млрд сум күләмендә бәяләнә.

Салым булмаган керемнәр берләштерелгән бюджет буенча – 22,4, республика бюджеты буенча – 17,3 млрд сум күләмендә фаразлана.

Федераль бюджеттан кайтарылмый торган керемнәр бюджет проектында 2024 елга 51,7 млрд сум күләмендә исәпкә алынган. Федераль чаралар төзелешен экранда күрәсез.

Чыгымнар

Алга таба – бюджет чыгымнары турында мәгълүматларга тукталып узам.

Чыгымнар буенча фаразларны формалаштыру федераль макроикътисадый индекс-дефляторларга нигезләнеп эшләнде. Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты чыгымнарының тәкъдим ителгән структурасы республика һәм җирле идарә органнарының чыгымнар буенча вәкаләтләрен финанслауны тәэмин итә.

Берләштерелгән бюджет чыгымнарында, өстәмә рәвештә, бюджет учреждениеләренең яңа челтәрен карап тоту, Рәис һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең йөкләмәләре, дәүләт һәм республика дәрәҗәсендәге чараларны уздыру исәпкә алынды.

2024–2026 елларга Татарстан Республикасы бюджетының, 45 муниципаль район һәм шәһәр берәмлегенең, 911 җирлекнең чыгымнары буенча фаразлары төзелде.

Бюджет чыгымнарын сыйфатлаучы аерым үзенчәлекләрне билгеләп узам.

Бюджетта беренче чираттагы һәм социаль әһәмияткә ия булган чыгымнарның дәрәҗәсе арта. Бюджет структурасында алар 84 процентка кадәр үсә. Нәтиҗәдә аларның үсеше берләштерелгән бюджетның капиталь характердагы чыгымнарын киметә.

Россия Президентының Май Указларын гамәлгә ашыра башлаганнан бирле, хезмәт хакын түләүгә чыгымнар ел саен арта бара. Бу хакта мәгълүмат экранда чагылдырылган.

Чыгымнарның дәүләт программалары буенча бүленеше дәвам итәчәк. Бюджет чыгымнарының программаларга кергән өлеше уртача 90,1 процент тәшкил итә.

Бюджетта берничә ел дәвамында гамәлдә булган социаль әһәмияткә ия чараларны финанслау каралган. Бу максатларга чыгымнар 7,4 млрд сум тәшкил итә. Аларның исемлеге слайдта күрсәтелгән.

Шулай ук бюджетта – резерв фондларын формалаштыруга, капиталь чыгымнарга, илкүләм һәм төбәк проектларын гамәлгә ашыруга, бюджет учреждениеләре тарафыннан милек салымын һәм җир салымын түләүгә, хезмәт хакын күтәрүгә акча каралган. Халыктан җыелган үзара салым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, бюджетара трансфертларны бүлеп бирүне дәвам итү тәкъдим ителә.

Тармаклар

Бюджет чыгымнарының аерым юнәлешләрен сыйфатлауга күчәм.

Бюджетның чыгым өлеше бюджет классификациясе нигезендә «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегеннән башлана. Бүлек буенча 24 елга берләштерелгән бюджет чыгымнарының гомуми күләме – 49,5, республика бюджеты буенча – 43 млрд сум күләмендә фаразлана. Әлеге бүлеккә Хөкүмәтнең резерв фонды чыгымнары һәм башка үзәкләштерелгән чаралар; Фәннәр академиясен һәм аның учреждениеләрен тоту керә.

«Илкүләм оборона» бүлеге буенча республика бюджеты чыгымнары 43,6 млн сум тәшкил итәчәк.

Чираттагы бүлек – берләштерелгән бюджет буенча чыгымнары суммасы 2,4, республика бюджеты буенча 1,7 млрд сум тәшкил иткән «Илкүләм иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге». Әлеге бүлек буенча Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын тоту һәм аның чаралары, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең бердәм диспетчерлык хезмәтләре эшен тәэмин итү һәм башкалар күздә тотыла.

Берләштерелгән бюджет буенча чыгымнары – 104,7, республика бюджеты буенча – 102,6 млрд сум тәшкил иткән «Илкүләм икътисад» бүлеге берничә тармакны берләштерә. Шулардан иң эреләре – юл хуҗалыгы, капиталь характердагы чыгымнар, авыл хуҗалыгы, транспорт.

«Торак-коммуналь хуҗалык» бүлегендә берләштерелгән бюджет буенча – 21,1, республика бюджеты буенча – 11,1 млрд сум күләмендә чыгымнар фаразлана.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау» бүлегендә берләштерелгән бюджет буенча барлыгы – 3,5, республика бюджеты буенча – 3,2 млрд сум күләмендә акча каралган.

Бюджет чыгымнарының иң зур бүлеге – «Социаль-мәдәни өлкә».

Социаль-мәдәни өлкәдә чыгымнар күләме буенча иң зур тармак – «Мәгариф». Бүлектә 24 елда берләштерелгән бюджет чыгымнары – 138,8, республика бюджетыныкы – 80,2 млрд сумга җитәчәк.

Әлеге чыгымнарда өстәмә рәвештә – укучылар контингентының үсүе, кадет интернатларында тәрбияләнүчеләрне тоту, йомгаклау аттестациясе үткәрү исәпкә алынды.

«Мәгариф» тармагында кайбер социаль республика максатчан программалары финанслана. Алар арасында – Татарстан Республикасында телләрне саклау һәм үстерү, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру, мәгариф учреждениеләренә капиталь ремонт ясау, ресурс үзәкләре булдыру, дәреслекләр сатып алу.

Социаль өлкәнең алдагы бүлеге – «Мәдәният, кинематография». Бүлек буенча 2024 елда берләштерелгән бюджет чыгымнары – 19,2, республика бюджеты буенча – 9,7 млрд сум күләмендә фаразлана. Чараларны грантлар бирүгә, китап фондларын туплауга, иҗади берлекләргә ярдәм итүгә, музейларны, театрларны, циркны, китапханәләрне, иҗат коллективларын тотуга юнәлдерү планлаштырыла.

Чираттагы бүлек – «Сәламәтлек саклау». Мәҗбүри медицина иминияте чараларын исәпкә алып, сәламәтлек саклауны тоту һәм үстерүгә чыгымнарның гомуми күләме – 108,4, республика бюджеты буенча 38,8 млрд сум тәшкил итәчәк.

Чираттагы бүлек – «Социаль сәясәт». Биредә берләштерелгән бюджет чыгымнары барлыгы – 60,3, республика бюджеты буенча 60,1 млрд сум күләмендә фаразлана. Әлеге күләмнәрдә агымдагы елда түләнә торган, инфляция дәрәҗәсендә индексацияләнгән барлык социаль пособиеләр һәм түләүләр каралган.

«Физик культура һәм спорт» бүлеге буенча берләштерелгән бюджет чыгымнары – 10,5, республика бюджеты буенча 4,1 млрд сум тәшкил итә. Чараларны спорт әзерлеге учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә, массакүләм спорт һәм югары казанышлар спорты өлкәсендә чараларны оештыруга һәм уздыруга юнәлтү каралган.

«Массакүләм мәгълүмат чаралары» бүлеге буенча 2024 елга чыгымнар республика бюджеты буенча 1,7 млрд сум күләмендә фаразлана.

Алдагы бүлек – «Дәүләт һәм муниципаль бурычны түләү». Әлеге бүлек буенча чыгымнар берләштерелгән бюджетта – 1,2 млрд сум, республика бюджеты буенча 857,2 млн сум тәшкил итәчәк.

Республика бюджетында йомгаклаучы булып, 2024 елга 26,9 млрд сум күләмендәге «Муниципаль берәмлекләр бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар» бүлеге килә.

Тулаем алганда, 2024 елга берләштерелгән бюджетның керем һәм чыгым өлеше 451,7 млрд сум күләмендә фаразлана. 2024 елга республика бюджеты керемнәр һәм чыгымнар буенча 383,9 млрд сум тәшкил итәчәк.

2025–2026 елга фаразны экранда күрәсез.

Хөрмәтле депутатлар!

2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына бюджет проекты Дәүләт Советы комитетлары утырышларында, парламент тыңлауларында һәм республиканың барлык районнары һәм шәһәрләре белән киңәшмәдә җентекләп тикшерелде.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, хөрмәтле депутатлардан закон проектын хуплауларын һәм аны беренче укылышта кабул итүләрен сорыйм.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ БЮДЖЕТ, САЛЫМ ҺӘМ ФИНАНС КОМИТЕТЫ РӘИСЕ ЛЕОНИД ЯКУНИН ЧЫГЫШЫ

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелгән «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проекты Бюджет кодексында күздә тотылган барлык күрсәткечләргә туры килә.

Бюджет проекты буенча республика Хөкүмәте белән уртак эш алып барылды, җәмәгатьчелектә, депутатлар берләшмәләрендә фикер алышулар узды, районнар, шәһәрләр, авыл җирлекләре вәкилләре белән видеоконференц-элемтә үткәрелде. Бюджет проекты парламент тыңлауларында каралды, Дәүләт Советының барлык комитетларында Экспертлар советлары катнашында анализланды. Бюджет проектын карап тикшерүнең барлык этаплары туры эфирда күрсәтелде. Проект буенча фикер алышуда барлыгы бер меңнән артыграк кеше катнашты. Тәкъдимнәр һәм искәртүләрне Дәүләт Советы исәпкә алды. Сүз уңаеннан, тыңлауларда яңгыраган тәкъдимнәр һәм сорауларга Хөкүмәттән җаваплар алынып, барлык депутатларга җибәрелде.

Финанс документын караганда һәр сан тикшерелде, шулай ук барлык дәүләт программалары барланды, планлаштырылган дәүләт средстволары чыгымнары аерым игътибар үзәгенә алынды.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: Россия Федерациясе Президентының, шулай ук республика Рәисенең Дәүләт Советына Юлламасында куелган йөкләмәләрен үтәү өчен ресурслар табу һәм, икътисадый вазгыятькә, санкцияләргә карамастан, халык алдындагы барлык социаль йөкләмәләрне үтәү төп финанс документын булдыруда иң мөһим бурычка әйләнде.

Быел Россия икътисадында тышкы һәм эчке шартлар тамырдан үзгәрде. Икътисадның яңа шартларга әкренләп кенә җайлашуы һәм үсешкә күчүе күзәтелә.

Шул ук вакытта өстәмә чыгымнар килеп чыгу һәм республика бюджетына керемнәрнең керми калу ихтималы сакланып кала. Моннан тыш инфляциянең көчәюе күзәтелә, моны 2024 елгы бюджетны үтәгәндә исәпкә алырга туры киләчәк.

Боларның барысы да алдагы чорда республика бюджеты сәясәте өлкәсендә төп бурычны – бюджет системасының балансын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү, шулай ук илкүләм үсеш максатларын тормышка ашыру зарурилыгына китерә.

2024 елга бюджет проектының төп өстенлекле юнәлешләре сыйфатында халыкка социаль ярдәм һәм бюджет өлкәсен үстерү билгеләнде. Беренче чиратта кирәкле социаль әһәмиятле чыгымнарга бюджет акчасының 80 процентан артыгракы юллана. Тәгаенләп әйтсәк, Татарстанның тупланма бюджетыннан – 360 миллиард сум чамасы.

Бюджет программалы булып кала, барлык чыгымнарның 90,1 проценты шуларга юнәлтелгән. Татарстан Республикасының 31 дәүләт программасын тормышка ашыруга акча каралган, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең аерым категорияләренә хезмәт хакын арттыру күздә тотылган, гавами норматив йөкләмәләрне үтәү чыгымнарын индексацияләү исәпкә алынган. Хезмәткә түләүнең минималь күләмен (МРОТ) сизелерлек арттыру (18,5%) бик мөһим булып тора, республика һәм җирле дәрәҗәдәге чыгым вәкаләтләрен үтәү каралган. Икътисадның тотрыклы үсүе дәвам итеп, өстәмә керемнәр алынган очракта, проектны тикшергәндә күтәрелгән мәсьәләләрне (бүгенгә аларга финанс ресурслары җитеп бетми) дә хәл итеп булыр дип уйлыйм.

Әлеге йөкләмәләрне үтәүнең төп шартларыннан берсе булып республика бюджетының керем өлешен арттыру, бюджет керемнәренең яңа чыганакларын эзләп табу, салым җыюның сыйфатын яхшырту, шулай ук аны күбрәк туплау буенча өстәмә чаралар күрү бурычы тора. Проектны 2023 елгы бюджет проекты белән чагыштырып, бюджет классификациясенең барлык статьялары буенча керем һәм чыгым күрсәткечләренең артуын әйтергә мөмкин.

Бюджет кодексында билгеләнгән чикләүләр проектта тулысынча үтәлгән.

Тулаем алганда, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджет бүгенге вазгыять өчен иң кулай һәм дөрес чишелешләргә нигезләнгән. Ул халык алдында барлык социаль йөкләмәләрнең төгәл үтәлешен һәм республика, аның ресурслары мөмкинлекләреннән чыгып, икътисадны үстерүне гарантияли. Инвестицион активлык һәм кулланучылар активлыгы, шулай ук эшкәртү производстволарын киңәйтү икътисадый үсештә төп этәргечкә әйләнергә тиеш.

Республика бюджетында төп өстенлекле мәсьәләләрнең берсе – гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларга, балалы гаиләләргә ярдәм итү.

Комитет 2024 елда бюджет сәясәтен тормышка ашыруда чиктән тыш ашыгыч һәм кичекмәстән бурычларны хәл итү өчен, Хөкүмәтнең резерв фондын арттыруны хуплый.

Бюджет юлламасына Хисап палатасыннан, Дәүләт Советының Хокук идарәсеннән, прокуратура һәм Иҗтимагый палатадан уңай бәяләмәләр алынды, шулай ук закон проектын Дәүләт Советының барлык комитетлары хуплады. Хокук идарәсенең һәм Татарстан Республикасы Прокуратурасының искәртүләре икенче укылышта исәпкә алыначак.

Өч еллык чорга бюджет проекты беренче укылышта кабул итүгә әзер. Комитетның карарын хуплауны сорыйм.

Депутатларга төзәтмәләрнең 10 ноябрьгә кадәр кабул ителәчәген искә төшереп үтәм.

Төзәтмәләрнең Дәүләт Советы Регламентының 100 статьясындагы 3 өлеше нигезендә рәсмиләштерелгән булуы кирәк.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

«Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы көн тәртибе турында» 2023 елның 19 октябрендәге 2161-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

«Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы көн тәртибе турында» 2023 елның 19 октябрендәге 2161-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына, аңа түбәндәге эчтәлекле 37 – 42 пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«37. «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 480-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

38. «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 495-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

39. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32^1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 491-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

40. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 496-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

41. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 499-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

42. «Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе алдындагы аерым казанышлар һәм зур уңышлар өчен өстәмә айлык матди тәэмин итү турында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 456352-8 номерлы федераль закон проекты турында (Изге Георгий ордены һәм Изге Георгий орденының аерымлык билгесе белән бүләкләнгән гражданнарны өстәмә матди тәэмин итү хокукын билгеләү хакында).».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2204-VI ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХИСАП ПАЛАТАСЫ РӘИСЕ АЛЕКСЕЙ ДЕМИДОВ ЧЫГЫШЫ

Татарстан Республикасы Хисап палатасы «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проекты буенча үткәрелгән экспертиза йомгакларын тәкъдим итә.

Беренче укылышка карап тикшерүгә кертелгән закон проектында дәүләт бурычы һәм аны түләү чыгымнары буенча, дефицитның чик күләме, бүленмичә калган средстволарның гомуми күләме буенча (пландагы чорга бюджет законында шартлы рәвештә расланган чыгымнар буларак каралган) Бюджет кодексында билгеләнгән чикләүләр үтәлгән.

Финанс министрлыгы, бюджет классификациясе кодларын билгеләү һәм тәгаенләштерү буенча Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләрен тормышка ашыру кысасында, кайбер үзгәрешләрдән, шул исәптән программалардагы чыгымнарны чагылдыру өчен кодлар булдыру эшен үзгәртүдән чыгып, бюджетны төзү өчен кирәкле база эшләгән. Киләсе елдан Татарстан Республикасы дәүләт программалары ике өлешкә: гавами хакимият органнары вәкаләтләрен тормышка ашыруны күздә тоткан өлешкә (проект өлеше) һәм идарә системасы эшен тәэмин итү өлешенә (процесс өлеше) бүленә. Мондый тәгаенләштерү алдагы чорга бюджет проектын эшләүдә яңалыкка әйләнде.

Финанс министры Радик Гайзатуллин чыгышының инде тыңлануын, шулай ук Дәүләт Советына юлланган бюджет күрсәткечләрен анализлау нәтиҗәләренең Хисап палатасы бәяләмәсеннән карап булуын истә тотып, керемнәр буенча фараз күрсәткечләрен гомуми рәвештә генә бәяләп үтәм. Алар – тормышка ашарлык дәрәҗәдә, закон проектында гамәлдәге законнарда күздә тотылган барлык керем чыганаклары исәпкә алынган.

Киләсе елга үз керемнәребез күләменең, агымдагы чорга башлангыч рәвештә расланган бюджет күрсәткечләре белән чагыштырганда, 17,8 процентка, ягъни 50 миллиард 199 миллион сумга артуы фаразлана. Салым керемнәренең барлык төрләре буенча үсеш көтелә.

2024 ел бюджетында кире кайтарылмый торган акча өлеше 13,5% тәшкил итә.

Хисап палатасы беренче укылышта каралган федераль бюджет проекты нигезендә кире кайтарылмый торган акчаның тулы күләмендә күздә тотылу-тотылмавын бәяләде. Анализдан күренгәнчә, ике күрсәткеч Татарстан өчен федераль дәрәҗәдә каралган күләмнән чыгып анықланырга тиеш. Республика Финанс министрлыгына бу хакта хәбәр ителде. Моннан тыш, финанслашу шартларын үтәү максатыннан чыгып, закон проектында алдан ук һөнәри әзерлек үзәкләрен булдырып куюга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә үз средстволарыбыз хисабына чыгымнар күләмен арттыру өчен нигезләр күрсәтелгән.

Хисап палатасы бәяләмәсендә федераль бюджеттан трансфертлар динамикасы тәкъдим ителә. Трансфертларның әлегә төрле юнәлештә булачагы күздә тотыла. Федераль бюджеттан кайбер керемнәр буенча, шул исәптән тапшырылган вәкаләтләрне үтәүгә субвенцияләр буенча күрсәткечләр үзгәртелергә мөмкин, чөнки өстәмә рәвештә максатчан средстволарның алынуы көтелә.

2023 ел бюджетында федераль бюджеттан керемнәрнең гомуми күләме, башлангыч фараз белән чагыштырганда, 4 миллиард 815 миллион сумга арттырылган.

2024 елга федераль бюджет проектында агымдагы елда республикага трансфертлар бирелә торган юнәлешләр буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында 317 миллиард сумнан артыграк акча бүленмәгән әле. Мәсәлән, гражданнарның аерым категорияләрен дарулар һәм медицина кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә, шулай ук инвалид балаларны сихәтле махсус ризыклар белән тәэмин итүгә средстволар. Агымдагы елда республика бюджетында бу максатка 1 миллиард 605 миллион сум күләмендә акча җибәреләчәге күздә тотылган.

Хисап палатасы бәяләмәсендә шулай ук чыгымнарның ведомстволар һәм функциональ структуралары, дәүләт программалары, гавами норматив йөкләмәләр, төрләре һәм алучылары буенча бюджетара трансфертлар ягыннан бюджет күрсәткечләре турында мәгълүмат бирелгән.

Закон проектында җирле бюджетларга акчалата трансфертлар күләме 2023 елдагы белән чагыштырганда 10,3 процентка артып, 72 миллиард 328 миллион сум тәшкил итәчәк.

Закон проектының чыгым өлеше, узган еллардагы кебек үк, илкүләм проектларның һәм дәүләт программаларының бурычларын хәл кылуга һәм максатларына ирешүгә юнәлдерелгән.

2024 ел бюджетында программаларга кертелгән чыгымнар 90 проценттан артыграк тәшкил итә. 31 дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру өчен күздә тотылган акчаны үз эченә ала. Федераль дәрәҗәдә проект принцибы нигезендә идарә итүне гамәлгә кертү һәм аны төбәкләр дәрәҗәсенә тарату юлы белән дәүләт программалары институтын камилләштерү агымдагы елда программаларны яңача эшләүне таләп итте. Республика Хисап палатасы, закон таләпләре нигезендә, яңа булдырылган проектларга финанс ягыннан экспертиза ясады, күрсәткечләрнең стратегик яктан өстенлекле бурычларга, Татарстанның социаль-икътисадый үсеше максатларына туры килүен бәяләде. Барлык программалар буенча бәяләмәләр Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Хөрмәтле депутатлар!

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча төп йомгакларны тәкъдим итәм.

1. Финанс министрлыгы белән фикер алышу нәтиҗәләре буенча икенче укылышка төзәтмәләр кертү планлаштырыла, алар бюджет проектындагы төп күрсәткечләргә йогынты ясамаячак.
2. Закон проекты бюджетны формалаштыру һәм аның эчтәлеге таләпләренә җавап бирә.
3. 2024 елга һәм план чорына бюджет тиешле балланска китерелгән. Фараздагы керемнәр һәм дефицитны финанслау чыганакларыннан керемнәр күләме планлаштырылган чыгымнарны тулысынча үтәүне тәэмин итә.

ЯРНЫҢ ЯРАЛАРЫН ЯМАГАНДА

Яшәргә өйрәнәбез

Табигатебез бик нечкә күңелле безнең. Игътибар беләнрәк карагыз әле: хәтта ерганаклар да елый бит. Шуңа күрә яр буйларындагы ачык яраларны ямарга кирәк.

Шул җәһәттән бу көннәрдә Казан дәүләт аграр университетының урман хуҗалыгы һәм экология факультеты студентлары белән мөгаллимнәре Балык Бистәсе районы ерганакларына яшь үсентеләр утырта. Бу юлы Алан-Полян авылыннан ерак түгел, М7 юлы өстендә тәҗрибә участогы итеп алынган ерганакта гөрләде эш. Дөресрәге, булачак урманчылар монда инде өченче ел агач утырта, тәҗрибәләр үткәрә, фәнни-тикшеренү эшләре алып бара.

...Күз күреме белән чамалаганда ун катлы йортны хәтерләткән ерганак кулларына Саба кылычы, китмән, кәйлә, көрәк, төрле үсентеләр тоткан студентлар белән чуарланган. Каен, нарат, карагач, ак сәрби, имән, тал кебек күп төрле агачларны аралаштырып утырталар. Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы җитәкчесе Нияз Тәҗмиев тә студентлар белән әвәрә килә, эш барышын бер дә күз уңыннан ычкындырмый. Бүген ерганакка 50 мең төп яшь үсенте утыртылачак. Шуларның 45 меңе – имән агачы.

Тәҗрибә участогы итеп нәкъ менә Балык Бистәсе районы зонасы юкка гына сайланмады. Үзем дә Күки авылында туып-үскән, кайчандыр хезмәт юлын Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгында башлап җибәргән белгеч буларак, туган ягым табигате миңа бигрәк тә таныш.

Ерганакларга агачны килдең дә утырттың гына түгел. Иң элек регионда табигатьне саклау максатыннан агачлар үстерү мөмкинлегенә анализ ясалды. Текә ераганакларда агач утыртуны тәэмин итү технологиясе эшләнде. Балык Бистәсе районының табигате, климат шартлары җентекләп өйрәнелде. Агач утыртучы студентлар гына түгел, фән белән шөгыльләнүче белгечләр дә бар биредә. Аспирант Рәзилә Сибгатуллина кандидатлык диссертациясен дә шушы темага яза. Аның янәшәсендәге студентлар да фәнни-тикшеренү эшләрендә бик теләп катнашалар. Әлеге эштә безгә Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ярдәм итә. Шулай ук, социаль тема дип, тәҗрибәләр белән республиканың Яшьләр эшләре министрлыгы да кызыксына, грантлар бирә.

Без урман-дала зонасында яшибез. Монда авыл хуҗалыгы җирләре бик нык җил һәм су эрозиясенә бирелә. Бүген төрле сәбәпләр аркасында күп кенә җирләребез юыла, ишелә. Хәтта бик текә, кеше үтеп йөри алмаслык кыялар барлыкка килә. Урман хуҗалыгы хезмәткәрләре, ерганакларга агач утыртып, аларны беркадәр җимерелүдән туктаталар, әлбәттә. Ә менә текә ярларга беркем дә алынмый. Без нәкъ менә шушы кеше кулы тимәгән урыннарга юл алдык та инде. Бу процесс озак дәвам итәчәк әле. Эшне берничә юнәлештә алып барабыз. Бердән, белгечләр әзерлибез, икенчедән, урман, фән белгечләренең белемен арттырабыз, өченчедән, туган җиребезне, аның бөтенлеген саклыйбыз.

Урманчылар фикеренчә, иң чыдамлы, иң сәламәт урман ул – структурасы белән катлаулы, күп ярулы, төрле яшьтәге һәм төрле исемдәге агачлардан торган урман. Шуңа күрә монда да имән янына нарат, корычагач, ак сәрби, спиреянең миләш яфраклысын утыртабыз.

Елына бер тапкыр килеп, агач утырту белән генә эш бетми, әлбәттә. Кар төшкәч, чаңгы эзе салып, шуның өстенә каен һәм сары сәрби орлыкларын чәчеп чыгабыз. Алар кар эчендә язгы тишелүгә әзерләнәләр, әкрен генә язгы сулар белән җиргә сеңәләр һәм, күмәк шытым биреп, үсеп китәләр.

Кыскасы, урманнарны торгызу буенча моңа кадәр нинди тәҗрибәләр әйләнештә булса, шуларны өйрәнеп, яңа ысулларны да кулланышка кертәбез. Ябык тамырлы имәннәр, кәлшәләр утыртабыз. Чәчеп үстергән урманнарның чыдамрак булуын исәпкә алып, имән чикләвеге дә чәчәбез. Җир астында алар язга кадәр тишелешкә әзерләнә һәм әйбәт шытым бирә. Аларны берәмләп җиргә күмгәндә, үзебез ясаган «Саба кылычы» дип аталган җайланманы кулланабыз. Ул ябык тамырлыларны утырту өчен уңайлы. Шулай ук «Колесов кылычы»н да файдаланабыз.

Студентларыбыз, белгечлек алгач та, әлеге эшләрне дәвам итәрләр дигән максат куйдык алдыбызга. Туган җиребезне үзебез сакламасак, аның турында кем кайгыртыр? Бу туфракта безнең әби-бабайларыбыз да, әти-әниләребез дә яшәгән. Шуңа күрә аны сау килеш киләчәк буыннарга тапшырасыбыз да бар.

Харис МУСИН

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык намуслы хезмәте, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасының лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итү буенча Анжела Вавилова исемендәге төбәк иҗтимагый хәйрия фонды идарәсе рәисе **Вавилов** Владимир Владимирович «**Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге баш белгече **Габбасова** Гөлнара Габделәзәл кызы, «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге шәһәр советы» муниципаль казна учреждениесенең оештыру-аналитик һәм хокукый эш идарәсе баш белгече **Зәйнуллина** Гүзәлия Мөнир кызы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлеге башлыгы **Кәримуллина** Гөллинә Рәхим кызы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы **Максимова** Наталья Викторовна, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга өлеш кертүе һәм торак сәясәтен үстерүдәге казанышлары өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең торак сәясәте бүлеге башлыгы **Абделмәнова** Гөлнара Райман кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераннары: **Мөхәммәтҗанов** Илдар Әнвәр улы, **Хәмидуллина** Нурия Габделхак кызы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Тямаева** Дания Фатыйх кызы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары: **Гадиева** Дания Абдулла кызы, **Заделенова** Наталия Васильевна, **Ившина** Людмила Петровна, **Милюкова** Марина Александровна, **Паткина** Валентина Михайловна, **Рәхимова** Надежда Ивановна, **Сабитов** Рөстәм Гомәр улы, **Сөләйманова** Әлфия Зәйнулла кызы, **Хансверова** Венера Әхмәт кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Кәнәфин** Марат Марс улына, Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Шакирова** Зөлфия Ингел кызына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

МАКАРОВ ВАЛЕРИЙ ВЛАДИМИРОВИЧ
(16.02.1965 – 02.11.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Әгерҗе районының элекке хакимияте башлыгы Макаров Валерий Владимирович озакка сузылган каты авырудан соң 2 ноябрьдә 59 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Валерий Макаров 1965 елның 16 февралендә ТАССРның Зәй шәһәрендә дөньяга килгән.

2002 елда – Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясен, 2018 елда «ТИСБИ» идарә университетын тәмамлаган.

Һөнәри эшчәнлеген 1989 елда Чаллы шәһәренең «Вита» кече предприятиесендә производство инженеры буларак башлап җибәргән. 1992–1996 елларда «Техтранс» фәнни-җитештерү фирмасы директорының транспорт буенча урынбасары, шуннан соң «Камагрострой» җитештерү предприятиесе директорының производство буенча урынбасары вазыйфасында эшләгән. 1998–2001 елларда «Бензин сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә җитәкчелек иткән. 2001 елда «Нефтеснаб» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры итеп билгеләнгән.

Валерий Макаров 2013 елда Әгерҗе муниципаль районы хакимияте башлыгы вазыйфасына сайланып, 7 елдан артыграк вакыт дәвамында район белән җитәкчелек итте. Аның тырышлыгы белән җирлекләр төзекләндерелде, торак-коммуналь хуҗалык системасының өзлексез эше тәэмин ителде. Торак һәм социаль-мәдәни объектлар төзү программалары тормышка ашырылды. Аерым алганда, «Олимп» спорт-савыктыру комплексы, балалар иҗат йорты калкып чыкты, «Орешник» паркын төзүгә керешелде.

Ул районда яшәүчеләрнең тормышын яхшырту мәсьәләсен игътибар үзәгендә тотты. Өлкән буынны даими кайгырту һәм ярдәм итүне өстенлекле эш юнәлешенә әйләндерде.

Валерий Владимировичның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм профессиональ казанышлары дәрәҗәле бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Фидакарь хезмәт өчен» медале, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте, Татарстан Республикасы министрлыкларының, ведомстволары һәм иҗтимагый оешмаларының Мактау грамоталары.

Валерий Макаров үзен көче-дәрте ташып торган югары квалификацияле, җаваплы җитәкче буларак танытты. Куелган максатка ирешүдәге ныклыгы, эшкә тугрылыгы, кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе аңа коллегалары арасында һәм җәмгыятьтә зур абруй-хөрмәт китерде.

Валерий Владимирович Макаровның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН, Н.Г. МӘҺДИЕВ, Л.Ф. НУРГАЯНОВ, Р.Г. КӘРИМОВ

Татарстан Язучылар берлеге, язучы, шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Дамир Минсәгыйрь улы ГЫЙСМЕТДИНОВның

вафаты сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Иҗтимагый палата» сүзләрен «1. Иҗтимагый палата» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Иҗтимагый палата җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплый һәм аның эшчәнлеген матди-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүдә ярдәм күрсәтә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 97-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексының 135^{4} статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексының 135^{4} статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативларга аучылык ресурсларын рөхсәт ителгән тартып алу нормативлары, биотехник чаралар нормативлары, шулай ук аучылык җирләре чикләрендә аерым аучылык ресурслары төрләренең минималь санын урнаштыруга таләпләр керә.»;

2) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативлар федераль закон нигезендә билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 98-ТРЗ

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү хакында тәкъдим барлык кирәкле документлар белән бергә җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кергән көннән алып бер айдан да соңрак булмаган срокта кабул ителергә тиеш.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 99-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2^{1} статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяның 11 өлешендә «9 һәм 16 статьяларында» сүзләрен «9, 15 һәм 16 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяның 13 өлешендә «9 һәм 21 статьяларында» сүзләрен «9, 20 һәм 21 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяда:

а) 13 өлештә «яисә рекреация билгеләнешендәге зоналарны ачыклау» сүзләрен «, рекреация билгеләнешендәге зоналарны ачыклау яисә торак пункт чикләренең җир кишәрлекләре чикләре белән кисешүен бетерү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 15 өлештә «9 һәм 25 статьялары» сүзләрен «9, 24 һәм 25 статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

5) 10^{1} статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1^{1} өлеш өстәргә:

«1^{1}. Бердәм документ әлеге статьяда һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28^{1} статьясында каралган таләпләр нигезендә ике һәм аннан артыграк җирлек, һәм (яисә) шәһәр округы, һәм (яисә) аларның составына керүче аерым торак пунктлар территорияләренә карата әзерләнергә һәм расланырга мөмкин.»;

б) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге статьяның 1^{1} өлешендә каралган бердәм документ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

6) 18 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «а» пунктчасы 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

3. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар, мондый документларга үзгәрешләр кертү турында карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 8^{1} һәм 18 өлешләре («Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) редакциясендә) нигезендә территорияне планлаштыру документларын әзерләүнең һәм раслауның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртипләре үз көченә кергән көнгә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән булса, мондый карар нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын, мондый карар нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләрне раслау Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 8^{1} һәм 19 өлешләре (Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциядә), «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2^{1} статьясындагы 2 өлешенең 6 пункты һәм 18 статьясы (әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциядә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 100-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7^{2} пункт өстәргә:

«7^{2}) хосусыйлаштырылганда газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектларына салынган эксплуатация йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели;»;

2) 8 статьяның 2 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

«Газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектлары хосусыйлаштырылган очракта, аларны эксплуатация йөкләмәләре белән чикләп тору хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарга мөһим шарт буларак кертелергә тиеш.»;

б) ундүртенче һәм унбишенче абзацларны тиешенчә унбишенче һәм уналтынчы абзацлар дип санарга;

3) 10 статьяда:

а) исемендә «Акционер җәмгыять акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын» сүзләрен «Дәүләт мөлкәтен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «(тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба – мәдәни мирас объектлары)» сүзләрен «(тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба – мәдәни мирас объектлары), газ бүлү челтәрләрен, газ куллану челтәрләрен һәм мондый челтәрләр объектларын» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «объектларына» сүзеннән соң «, газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә торышы канәгатьләнмәслек дип танылган мәдәни мирас объектын әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә саклап калу буенча эшләр үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы нигезендә башка шартлар.»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны тиешенчә тугызынчы һәм унынчы абзацлар дип санарга;

4) 15 статьяның 1 өлешендә «күрсәтелгән объектлардан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр» сүзләрен «мондый объектлардан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр, мондый объектларда һәм аларның территорияләрендә тышкы реклама урнаштыруга таләпләр, шулай ук мәдәни мирас объекты турында мәгълүматы булган язмалар һәм билгеләр урнаштыруга таләпләр» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 101-ТРЗ

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы булып кече һәм урта эшкуарлык субъектларын булдыру өчен шартлар тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларны), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашырганда дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру һәм аларга ярдәм итү өчен тәэмин итүчеләр (башкаручылар, подрядчылар) сыйфатында булдырыла, үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра яисә җәлеп ителә торган коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар системасы тора.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 1^{1} өлеш өстәргә:

«1^{1}. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасына шулай ук түбәндәгеләр керә:

1) эшкуарлыкны үстерү үзәкләре һәм агентлыклары;

2) эшкуарлыкка ярдәм итүче дәүләт фондлары һәм муниципаль фондлар;

3) кредитлаштыруга булышу фондлары (гарантия фондлары, поручительлек фондлары);

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен инвестицияләр җәлеп итү фондлары;

5) технопарклар һәм технопарклар белән идарә итүче оешмалар;

6) инновация-технология үзәкләре;

7) бизнес-парклар һәм бизнес-парклар белән идарә итүче оешмалар;

8) бизнес-инкубаторлар;

9) һөнәрләр палаталары һәм үзәкләре;

10) субподрядка ярдәм итү үзәкләре,

11) маркетинг һәм уку-эш үзәкләре;

12) экспортка ярдәм итү үзәкләре,

13) лизинг компанияләре;

14) консультация үзәкләре;

15) индустрия (сәнәгать) парклары һәм индустрия (сәнәгать) парклары белән идарә итүче компанияләр;

16) сәнәгать технопарклары һәм сәнәгать технопарклары белән идарә итүче компанияләр;

17) технологияләрне коммерциальләштерү үзәкләре;

18) югары технологияле җайланмалардан күмәк файдалану үзәкләре;

19) инжиниринг үзәкләре;

20) прототиплаштыру һәм сәнәгать дизайны үзәкләре;

21) технологияләрне трансферлау үзәкләре;

22) кластер үсеше үзәкләре;

23) эшчәнлекләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра торган фәнни, фәнни-техник эшчәнлеккә, инновация эшчәнлегенә ярдәм итүче дәүләт фондлары;

24) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга микрозаемнар бирүче микрофинанс оешмалары;

25) социаль өлкә инновацияләре үзәкләре;

26) сертификацияләү, стандартлаштыру һәм сынау үзәкләре;

27) халык сәнгать кәсепләренә ярдәм итү үзәкләре;

28) авыл һәм экология туризмын үстерү үзәкләре;

29) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хезмәт күрсәтүче дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре;

30) сәүдә-сәнәгать палаталары;

31) авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләре;

32) финанс агентлыклары;

33) кооперативлар;

34) хокук үзәкләре;

35) махсуслаштырылган җитештерү территорияләре (җитештерү-технология зоналары);

36) бизнес-кунакханәләр;

37) фәнни-тикшеренү оешмалары;

38) технополислар белән идарә итүче оешмалар;

39) фәнни парклар һәм фәнни парклар белән идарә итүче оешмалар;

40) агросәнәгать парклары һәм агросәнәгать парклары белән идарә итүче оешмалар;

41) бүтән оешмалар.»;

2) 18 статьяның 5 пунктында «технопарклар,» сүзеннән соң «бизнес-парклар,» сүзен өстәргә;

3) 21 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1^{1} пункт өстәргә:

«1^{1}) авыл хуҗалыгы кооперациясе һәм фермерларга ярдәм итү өлкәсендә компетенцияләр үзәкләрен булдыру һәм мондый үзәкләр эшчәнлеген тәэмин итү;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 102-ТРЗ

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) югары технологияләр өлкәсендәге технопарк – сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновация эшчәнлеген, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан идарә ителә торган технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларының, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның җыелмасы;»;

б) 2 өлештә «Федераль законда» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «әлеге Законда» сүзләрен «Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8) югары технологияләр өлкәсендәге технопарк – сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновация эшчәнлеген, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан идарә ителә торган технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларының, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның җыелмасы.»;

2) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктта «идарәче компанияләренә,» сүзләреннән соң «югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә,» сүзләрен өстәргә;

б) 7 пунктта «технопаркларына» сүзеннән соң «, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга» сүзләрен өстәргә;

в) 11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяның 4 өлешендә «органы» сүзеннән соң «(алга таба – икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган)» сүзләрен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле 12^{2} статья өстәргә:

«12^{2} статья. **Югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар**

1. Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенә һәм сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновация эшчәнлеген, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның составында булган технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларыннан, биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдаланучы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән өстәмә таләпләргә туры килгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан югары технологияләр өлкәсендәге технопаркка һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенә карата өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенең аларга туры килүен раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

3. Икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен расланган югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләре реестрын алып баруны гамәлгә ашыра. Әлеге реестрны алып бару тәртибе күрсәтелгән вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.»;

5) 19 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) конгресс һәм (яисә) күргәзмә чаралары, ярминкәләр (шул исәптән халыкара) үткәрүне оештыру яисә аларны үткәрүдә ярдәм итү аша;».

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 103-ТРЗ

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең «в» пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2007, № 10), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) квалификация комиссиясе әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;».

2 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясындагы 8 өлешенең 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), «комиссия әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы бетерелгәндә, ул чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алганда» сүзләрен «комиссия әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда яисә ул чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алганда» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 104-ТРЗ

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2007, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) бишенче өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяда «учреждениеләренең, оешмаларының һәм предприятиеләренең» сүзләрен «оешмаларының» сүзенә алмаштырырга;

4) 9 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 10 статьяның дүртенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 11 статьяның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре үз компетенциясе чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген координацияләү буенча Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләт тапшырган орган кушуы нигезендә түбәндәгеләрне башкаралар:»;

7) 12 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 14 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

9) 15 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

10) 16 статьяда икенче җөмләне төшереп калдырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 105-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә:

«41) җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

2) 16 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 36 пункт өстәргә:

«36) муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

3) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 45 пункт өстәргә:

«45) шәһәр округы милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 106-ТРЗ

ҖЫЛЫ КУЫШ

Авыл капкасы

Читтән бәхет эзләмичә, туган авылларындагы төп нигезне таратмыйча, шунда балалар, ә аннан соң оныклар үстереп, бик тырышып матур гомер иткән гаиләләр бар. Мөслим районының Мәллә Тамак авылында яшәүче Гөлүсә һәм Рөстәм Сәлаховлар – әнә шундыйлардан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Без килеп кергәндә, хуҗабикә аш плитәсе тирәсендә бөтерелә иде. Йорттагы җылылык, рәхәтлек, яктылык урамда туңып кергәннәрне бер минут эчендә юды да төшерде. Бу рәхәтлек өйгә хуш ис тараткан өчпочмакка гына түгел, хуҗаларның, өстәл тирәсендә бөтерелгән балаларның күңел халәтенә дә бәйле иде. Шулай булмый ни! Үзләре белән бер йортта яшәүче киленнәре Илсөяр бер сәгать элек кенә өченчегә әни булган икән. Гөлүсә апаның телефоны тынып тормый: барысы да бәби туу шатлыгын уртаклаша. Үзе Рөстәм абыйга ихластан елмаеп: «Иии, Илсөяребез дә котылды бит!» – дип, куанычын белдереп ала. Балалар да: «Ә безнең энебез бар!» – дип, безнең тирәдә йөгерешеп йөри. Менә шундый бик сөенечле мизгелләренә туры килдек Сәлаховларның.

– Бу – минем төп нигез. Балачактан ук әти-әни: «Син – төпчек, безне карап-тәрбияләп тору синең өстә булачак», – дип тәрбияләделәр, – дип, үзләре белән таныштырды гаилә башлыгы Рөстәм абый. – Шуңа күрә каядыр чыгып китү турында уйлаганым да булмады. Улым да чыгып китмәде, бер китсә, аның кире кайтмавы, ә нигезнең таралу куркынычы бар, дидек. Яшьләр белән яшәвебезнең төп хикмәте әнә шунда. Югыйсә үзләренә аерым йорт салып чыгарырга да мөмкинлегебез бар.

Балалар, оныклар – аерым бер тема. Әлеге күркәм гаиләдә өч бала тәрбияләнгән. Бүген инде оныклар сөяләр. Алар турында сораштыра башлагач, өлкәннәрнең күзләрендә очкыннар уйнаклый башлады.

> Бергә яшәүнең бер начарлыгын да күрмим. Бары бергә, югы уртак. Ике җиргә түләү түләмисең, бергә эшләп, бергә ашыйбыз. Оныклар үз балаларыбыздан да тәмлерәк. Үзебезнекеләрнең үскәнен күрми дә калдык, ә боларны яратып туеп булмый.

– Беркая да җибәрәсем килми. Мөслимгә китә калсалар, бу оныклардан башка ничек яшәмәк кирәк? – дип сүзгә кушылды хуҗабикә Гөлүсә апа да. – Илсөяр киленебезне үзебезнең балабыз шикелле яратабыз. Оныклар турында әйтеп тә тормыйм инде. Илсөяр барысына да бик оста, кухняда да, бакчада да ут өертеп эшли.

Рөстәм абый да, уллары Алмаз да – алдынгы механизаторлар.

– Колхозда беренче чирканчыкны 5 нче сыйныфта алган идем. Ул вакытта ашлык китерү цехында, 8–9 сыйныфларда оператор булып эшләдем. Әле дә шаккатам, яшүсмер малайга нинди зур ышаныч булган. Шуңа күрә армиядән соң туп-туры авылга кайттым да колхозга эшкә урнаштым, – дип искә алды ул чорларны Рөстәм Сәлахов. – Колхозда эшләгән еллар яшьлеккә туры килде. Шуңа күрә авырлыгы булса да, бер дә сизелмәгәндер, дип уйлыйм. Яшьлек дәрте, яшьлек егәрлеге белән батырып эшләдек. Тәүлегенә 24 сәгатьне дә җиткерә алмый идек. Хәзер, әлбәттә, яшь барган саен, һәр нәрсә башка төрле кабул ителә. Ул заманнарда техникасы да шуның төсле генә иде. Хәзер бик көчле, иң заманча тракторларда, комбайннарда җилдерәбез. Эшләр өчен барлык шартлар да бар.

Армиядән кайтып, колхозга урнашуына да 43 ел вакыт узган да киткән. Бүген әтиле-уллы Сәлаховлар «Август Мөслим» агрофирмасында хезмәт куя. Рөстәм абый җәен кыр корабын иярләсә, елның башка вакытында трактор йөртә. Алмаз исә тракторда эшли.

– Хәзер кышын хуҗалыкта эш юк инде, аның каравы җәен яхшы гына эшлибез. Тырышып эшләгәч, акчасын да мулдан алабыз. Тоткарлыксыз биреп баралар. Язгы чәчүдә 100 мең сумнан артык алсак, урыпҗыю чорында айлык хезмәт хакы 200 мең сумнан артып китте. Быел безнең яклар яңгырга тилмерде, язын бик әшәке кыраулар сугып, шактый сыналдык. Ләкин уңыш елына күрә начар булмады. Авыл хуҗалыгында тырышып эшләүдән бигрәк, һава торышы бик зур роль уйный шул. Ә җир эшен бик яратам! Монда яратмыйча эшләп булмый. Улым да үземә охшаган. Мәктәптә укыганда ук минем белән комбайнда йөрде. Минзәлә техникумында укыган чакта инде җир эшкәртте, чәчү чәчте. Башка эшкә дә урнашып караган иде, тик күңеле барыбер авылга, җиргә тартылды, – дип горурлана улы белән Рөстәм Сәлахов.

Авылда гаилә башлыгын кайчандыр әти-әнисенең үгет-нәсыйхәте алып калган булса, бүген бу бурыч – уллары Алмаз җилкәсендә.

– Мин туганнан бирле авылда, әтинең кул арасына кереп үстем, – ди ул. – Гаиләдә бер малай булгач, нигез өчен дә, әти-әни өчен дә җаваплылык тоям. Бергә яшәүнең уңайлыклары күбрәк. Авыл хуҗалыгында эшләгәч, өйгә кайтып кереп булмый. Беребез бер эшне эшләгәндә, икенчебез икенчесен башкара. Хуҗалыкны бергә алып барабыз. Балаларны тәрбияләүдә дә әти белән әнинең өлеше зур. Шәһәргә чыгып китү турында уйлаганым да булмады. Авылда калыр өчен эш сөю кирәк. Ә инде өлкән буын белән бергә яшисең икән, әти-әнинең яхшы булуы, бер-беребезне аңлау кирәк. Бу яктан минем күңелем тыныч. Хатыным Илсөяр белән уртак телне тиз таптылар.

Гаилә ишле булгач, абзардагы мал-туарны да бетермәгәннәр. Болар өстенә күпләп кош-корт алып үстерәләр.

– Терлек барда тамак тук. Сыерларыбыз да, үгез, бозауларыбыз да бар. Тик берсе дә сатар өчен түгел. Барысын да үзебез һәм балалар өчен дип үстерәбез. Сөтен-каймагын да, итен дә бергә ашыйбыз. Аның рәхәте дә шунда. Ялкауланып китмәс өчен дә бер сәбәп. Урамга чыгып, буыннарны язып, һава сулап керүгә дә яхшы. Малларга азыкны сатып кына алабыз, чөнки үзебезгә әзерләргә җай чыкмый. Акчасын түләгәч, сатып алу авырлык китерми, – ди Рөстәм Сәлахов.

Менә шулай бар сөенеч һәм көенечләрен бер казанга салып, һәр көннең рәхәтен һәм тәмен белеп яши әлеге матур гаилә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИСРАФ ҮТМӘСЕН МИНУТЛАР

Яңашәбездә

Чистай районының Татар Баганалысы авылы музеена килеп керсәк, берәү җырлый-җырлый йон эрләп утыра. «Безнең Гөлнур апа кебек кеше дөньяда юктыр. Бөтерчектән бер дә ким түгел ул», – дип таныштырдылар мәдәният йортында эшләүче кызлар.

Житмеш яшьлек җырчы апа белән без дә якыннанрак таныштык. Чыннан да бик өлгер апа булып чыкты ул. Менә инде ун ел мәчеттә белем бирә икән. Кырыклап шәкерте бар. Үзе авылда нинди вакыйга булса, шунда йөгерә: мәет булса да, бәби туса да, авырып китсәләр дә Гөлнур апасыз булмый. Музейда җырлап утыруы да юктан гына түгел. Беренчедән, ул җыр-биюгә бик оста. Мәдәният йортында оештырылган ансамбльдә дә җырлый. Икенчедән, шунда ук кул эшләре түгәрәген җитәкли. «Искиткеч оста, чигү алымнарын да бик шәп өйрәтә, бәйләүне дә. Чистай Сабан туенда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка да Гөлнур апа чиккән кулъяулыкны бүләк иттек. Күргәзмәгә куелган курчакларга кадәр киемнәрне үзе тегә, бер дә иренеп тормый», – диеште кызлар.

Үзе сөйләгәннәрдән дә тынгысыз икәнлеге күренеп тора Гөлнур апаның.

– Бер минутымны да исраф итәргә яратмыйм. Кечкенәдән шулай өйрәнгән инде. Әти-әниләрем гади кешеләр булса да, бик уңган, булган, кунакчыл, шат күңелле иде. Мәктәптә дә бик актив булдым. Отряд, дружина советы председателе булып та эшләдем. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Бөгелмәгә кибетчелеккә укырга киткән идем. Өйдә җиде бала калды. Миннән соң да дүртәү бит әле. Бик авыр яшәүләрен күрдем дә, аларның өлешенә керәм инде, дип уйланып йөри торгач, түзә алмадым, кайтып, колхозга сыер савучы булып эшкә урнаштым. Әти фермада хайван карый, әни терлек симертә, апам сыер сава, абыем – көтүче. Тормышны бергәләп тарттык. Ул вакытта миңа нибары 15 яшь иде. Улакка буем җитми, бармакларым кечкенә. Кул белән 16 сыер савасы. Тешемне кысып булса да түздем, бирешмәдем. Тик барыбер кыенга туры килде инде: биш елдан соң авырып киттем. Әмма авылдан китү турында уйлап та карамадым. Табиблар, җиңел эш кирәк, дигәч, клубка, декрет ялына киткән кеше урынына сәнгать җитәкчесе булып урнаштым. Бәхетемне дә шушы авылда таптым. Моннан нәкъ 50 ел элек Рудаль исемле егет белән тормыш корып җибәрдек. Шул вакытта балалар бакчасына няня итеп куйдылар. Аннан үземнең бер-бер артлы өч улым туды. Эштән китеп торырга туры килде. Балалар үсә башлагач, төрле эшкә йөри башладым. Идән дә юдым, пешекче дә булдым, тәрбияче дә, сатучы да… 1984 елда авылда трикотаж фабрикасының филиалын ачканнар иде. Шунда тегүче булып урнаштым. Тәҗрибәм бар иде. Өченче сыйныфта чакта ук шәл кырыйлары, оекбашлар бәйли идем…

Нәкъ әкияттәгечә, өч егет үстерәләр Рудаль абый белән Гөлнур апа. Өчесе дә армиядә хезмәт итәләр. Өчесе дә хәрби конфликтларда катнашалар. Айрат белән Айнур – Чечняда, Айдар – Абхазиядә. Айдар белән Айрат гаилә корганнар, балалар үстерәләр. Тик менә Айнурлары гына, йөрәкләрен яралап, бакыйлыкка күчкән. Контузиядән соң тернәкләнеп китә алмаган. Бүген бу гаиләнең җиде оныгы бар. Киленнәрдән дә бик канәгать алар. «Бик әйбәтләр», – дип сөенә Гөлнур апа. Барысына да бәрәкәтле тормыш тели.

– Гөлнур апа – барыбыз өчен дә үрнәк, – диләр авылдашлары. – Җитешмәгән җире, эшләмәгән эше юк. Өе дә пөхтә, һәр почмагы ялт итеп тора. Аның кебек кеше булмас…

Авылдашлар мактый, ә минем башымда гел бер сорау әйләнә: ни өчен берәүләр кечкенә генә әйберләрдән тәм табып яши, икенчеләрнең зарланудан башы чыкмый? Сөйләшеп утыра торгач, җавап та таптым кебек. Гөлнур апа нәрсәдер эшләргә, булдырырга, җиренә җиткерергә омтылып яши. Омтылыш дигән хис көчле анда. Шул хис аңа яшәргә көч бирә. Бу аның һәр гамәленнән, кешеләргә, күренешләргә булган мөнәсәбәтеннән сизелеп тора.

– Әти-әнием вафат булгач, нигезебез какшый башлады. Бик эчем пошты инде. Әнием дә төшкә керде. Келәт почмагына баскан да: «Нигезне бетермәгез, тергезегез», – ди. Түзмәдем, яңарттым да Коръән укыттым. Туганнарым кайтса да, башта нигезебезгә юнәләбез. Бик рәхәт, җылы учак кебек ул. Йөз еллык нигез инде ул. Бер дә чит кешеләр кертәсе килми. Һәр ел саен мәҗлес җыям, туганнарымны чакырам. Ата-ана нигезе яшәргә дәрт бирә.

– Уку теләге көчле иде. Вакытында мөмкинлек булмаса да, тора-бара барыбер җаен таптым. 35 яшемдә Лаеш техникумына читтән торып укырга кердем. Мәктәптә лаборант булып эшләдем, шуннан пенсиягә чыктым. Дин белеме дә аласым килде. Чистайга киттем дә башта бер мәчеткә кердем, анысында барып чыкмады. Икенчесендә бик матур каршы алдылар. Теләгең булса, кил, диделәр. Читтән торып укып чыктым. Шулвакыт бер дус кызым: «Әйдә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә кер», – дип тәкъдим итте. Иремә дөресен әйтергә яхшысынмадым. «Срочно Казанга барасым бар иде», – дип чыгып киттем. Уку йортына кереп үк кайттым. Шөкер, ирем каршы килмәде. Тәмамлап чыктым шулай. Әмма гыйлемле булу теләге һич кенә дә сүрелмәде. Авыл имамы белән сөйләшкәч, ул Ислам институтына керергә тәкъдим итте. Быел гына имтиханнар бирдем. Укып йөрим.

– Истәлекләр, шигырьләр язарга яратам. Кайгылы вакытларда бәетләр язам. Киленем вафат булгач, Чистайга бала карарга бардым. Идәнгә яттым да бер төн эчендә бөтен тормыш мизгелләрен искә алып чыктым. «Әни, сава торган сыерыңны бетереп булса да, мине кара инде. Картайгач, үзеңне карармын», – дигән иде җанашым. Шулай эшләдем дә. Тик алып калып кына булмады.

– Балалар сугышка киткәнне беркемгә дә әйтмәдем. Бервакыт шулай чәй эчеп утырабыз. Мәктәп завучы: «И, бу баланың эчендә ут яна бит. Балалары сугышта бит моның», – ди. «Безнең язмышка беркем дә гаепле түгел. Малайларым үзләре шулай теләделәр», – дидем.

Чәчәкләр үстерергә дә ярата икән Гөлнур апа. Яшәгән йорты да, туган нигезе дә, мәдәният йорты бакчасы да аның куллары белән шау чәчәккә күмелгән. Омтылыш хисе шундый бит ул: эш-гамәлләрне дә, белемне дә, гыйлемне дә, матурлыкны да үз итә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Соклану

Туфан авылы

Күптән түгел Кама Тамагы районының Олы Мәрәтхуҗа авылында булып кайттым. Хәмит Рәфыйков дигән егет: «Мәчет ачабыз, тантанада син дә катнашсаң, әйбәт булыр иде», – дип шалтыратты. «Мәчеткә Туфан исеме кушасызмы?» – дип сорагач, Хәмит аптырап калды. «Без аны болай да «Туфан мәчете» дип йөртәбез. Гомумән, авылда бөтен нәрсә Туфан абыйныкы: газы да, суы да, электры да, чишмәсе дә», – дип тезеп китте.

Авыл халкы мәчетне дә Туфан ага төзеткәнне белә, шуңа күрә исем кушу турында уйлаганнары да юк. Хәмит әйтүенчә, хәзер авылның исемен дә әйтеп тормыйлар икән. «Туфан авылы» дигән сүзнең Олы Мәрәтхуҗа турында барганлыгын беләләр, чамалыйлар.

«Олы» дисәләр дә, зур түгел бу авыл. Өч дистә чамасы йорт бар, әмма яши әле һәм Җир йөзеннән юкка чыкмас та, шәт. Чөнки халкының яшәү рәвеше Туфанча. Алар авылның милләтне, телне, йола-гадәтләрне, татарның күркәм сыйфатларын саклаганын беләләр. Туфан ага Миңнуллин да гомере буе авыл өчен җан атып яшәде. Татар авыллары язмышы турында зур мөнбәрләрдән дә сөйләде ул, авылының гомерен озайту өчен изге гамәлләр дә башкарды. Әле колхозлар чорында ук алар хуҗалык рәисе Рафаэль Гыймадиев белән бергә, яшьләрне авылда калдыру өчен, әллә нинди планнар корганнар. Ниятләре кәгазьдә һәм сүздә генә калмаган. Авылда калырга теләгән яшьләр, белгечләр өчен колхоз дистәгә якын йорт салган. Хәмит Рәфыйков кеше гомердә ышанмаслык бер кызыклы эш турында сөйләде. Авыл егетләренең армиядән кайту көннәре якынлашканда, аларның капка төпләренә колхоз машиналарын китереп куялар икән. Бу инде: «Энем, менә сиңа машина, шуңа утыр да колхозда эшлә!» – дигәнне аңлаткан. Һәм утырганнар да егетләр машинага. Хәмитнең кияве Илфат – шундыйларның берсе. Бүген авылны, Туфан рухын саклау өчен нинди генә эшкә тотынсалар да, Илфат һәрвакыт Хәмитнең уң кулы булыр. Ә Хәмит Рәфыйков – Туфан аганың күршесе. Үзе Казанда чакта әдипнең йорт-җиренә күз-колак булып яшәгән егет. Аны үзе артында хәзер дә «Туфан малае» дип йөртәләр. Кайберсе үги малае түгелме икән дип тә шаярткалый. Моны ишеткәч, Хәмит үзе дә шаяртып: «Их, булсам иде әле!» – дип әйткәли, имеш.

Гаҗәп бердәм бу авыл халкы. Туфан – авыл өчен, безнең өчен яшәде, хәзер без аңа әҗерен кайтарабыз, дип, һәр эшкә күмәкләшеп тотыналар.

Мине мәчет ачу тантанасына дип чакырсалар да, бу вакыйгада рәсмилекнең исе дә юк иде. Мәчет яңа түгел, еллар узып шактый тузган. Шуңа күрә авыл кешеләре уйлашканнар да яңартырга булганнар. Үзара акча да җыйганнар. Төп иганәчеләре – Марсель Газизов. Иң кызыгы, ул үзе монда тумаган, әти-әнисе Мәрәтхуҗа кешеләре икән. Төзекләндерү эшләренә җитәкчелек итүче иганәче Илдар Вафин исә – Туфан агага туган тиешле егет.

Төзекләндерү өчен иң беренче акчаны Хәмитнең улы Илназ биргән. Ул махсус операциядә катнаша икән. Ялга кайткан булган да, мәчетне яңартуларын ишеткәч, миннән дә өлеш булсын дип, акча чыгарган да биргән, ди. Хәмиттән хәлләрен сораштым. Зарланмый икән Илназ, телефоннан «бездә бөтенесе дә тәртиптә» дигәнрәк хәбәрләр җибәреп тора ди. Хәмит әйтүенчә, егет фронтка үзе теләп киткән. Әтисенең бераз икеләнүләрен сизгәч: «Әти, мин дә полосатый, син дә полосатый, минем урында булсаң, үзең нишләр идең?» – дип кенә куйган. «Полосатый» дигәне десант гаскәрләрендә хезмәт итүне аңлата. Хәмит нәрсә дисен: «Үзең хәл иткәнсең бит инде, молодец, улым!» – дигән. Илназ быел декабрьләрдә тагын ялга кайтырга тиеш икән (исән-сау гына булсын инде егетебез).

Мин яңартылган мәчетне ачканда кемнең нәрсә әйткәнен тәфсилләп язып тормыйм. Кәҗүнни сүзләрдән торган аерым чыгышлар булмады. Мәчет эшенә үз өлешен керткәннәрнең исемен халык үзе атады. Авылдашлардан рәхмәт ишетү күңеллерәктер дә әле ул.

Халык шактый җыелган иде монда. Социаль челтәрдәге «ВКонтакте» аша мәчет ачыласын белеп, Казаннан, Чаллыдан кайтучылар да бар иде. «Озын ялга түгел, мәчет ачуда катнашыр өчен махсус кайттык», – диделәр.

Мин Туфан абый авылы халкының бер җан булып яшәвенә ышанам. «Ни җитми, нәрсә эшләргә кирәк – утырып сөйләшәбез дә эшкә тотынабыз!» – ди Хәмит. Ул үзенең һәрнәрсәдә башлап йөрүче икәнен әйтми, сиздерми. Тик авыл халкы моны белә, рәхмәт укый. Туфан рухына тугрылыклы булып яшәүләренә шатланалар. Бетерерсең мондый авылны!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Үзгәрү

Без һәрвакыт кешелекнең үсеше турында сөйләргә яратабыз. Бу рәхәт, үзебезне зур итеп тоярга, горурланырга мөмкинлек бирә. Һәм без бер мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмаска тырышабыз.

Очраклы рәвештә генә бер Сабан туена эләктем. Хәзер ул бездә сәеррәк рәвеш алды бит инде: ниндидер эстрада йолдызларын чакыралар да, бөтен ыгы-зыгы шулар тирәсендә уза. Көрәшне дә, атлар чабышын да, башка уеннарны да күрми калалар. Минем әллә ничә җырчыны күргән бар инде, шуңа аларга бик исем китмәде, күзне сөендерерлек мәзәк эзләп, мәйдан буйлап йөрендем. Эзләгән эткә сөяк табыла, диләр…

Бер ханым бәйрәмгә этен ияртеп килгән. Һәм иң кызыгы, ул этен киендереп алып чыккан. Көн матур, кояш елмая, назлы җил иркәли. Шуңа теге ханым үзе дә, артыгын киенеп, чүпрәк әрәм итмәгән. Һәрхәлдә, аның киеме ирләр күзе төшә торган урыннарын бик матурлый, хыял үткерләрлек дәрәҗәгә җиткерә. Итәкләре дә Чехов хикәяләре кебек: кыска һәм калганын үзең уйлап бетерү өчен. Гаепләп әйтмим инде, сокланып әйтәм. Сокланырлык сәламәтлегең булганда, бер матурлыкны да гаепләргә ярамый. Ләкин этен тагы да купшырак итеп киендергән: ялтырап торган күлмәк, аның өстеннән – камзул. Хәтта башында түбәтәе дә бар. Чып-чын татар эте инде, хәләл эт. Муенына әллә нинди ялтыравыклы медальләр аскан, матур итеп зеңли торган кыңгыравы да бар. Эт үзе дә соклангыч, дәрәҗәсен белеп кенә атлый, хуҗабикә әйткәнне үти. Хәтта ул җиргә ташлаган туңдырма кәгазен дә чүп савытына илтеп килде. Мин боларны озак кына күзәтеп йөрдем. Ул эт мине чын-чынлап хәйран итте. Кайчагында хәтта аның эт булуына да шикләнеп куйдым. Бары тик кемнеңдер җиңел машинасыннан үләнгә сикергән песи баласын күргәч кенә… Ничек кенә киендерсәң дә, нинди һөнәрләргә генә өйрәтсәң дә, нинди генә тәрбия бирсәң дә, эт барыбер эт булып кала инде… Аннан артыгын көтәргә кирәкми…

Песи дә шул. Барлык җәнлек-җанвар да. Без аларны яки матур итеп киендереп, яки ниндидер һөнәрләргә өйрәтеп, яки башка юллар белән гадәттән тыш күренешкә әйләндерәбез. Шулай иткәч, асылы да үзгәрәдер, алар бүтән кардәшләреннән акыллырак, яхшырак буладыр, дип уйлыйбыз.

Җәнлек-җанвар гына түгел… Агачлар да, чәчәкләр дә, бүтән үсемлекләр дә… Әйе, матур итеп утыртып, тигезләп кисеп торсаң, әйтик, куаклар бик соклангыч тоела. Матур түтәлләрдә бик әйбәтләп тәрбияләп үстергән чәчәкләр дә шаккатарлык булып күренә. Сәнгать әсәре инде менә. Хәтта гади генә чыршы да. Яңа ел алдыннан бик тырышып бизибез бит инде без аны. Күз явын алырлык дәрәҗәгә җиткерәбез дә шуңа карап сокланабыз, уртага алып бии-бии әйләнәбез, җырлар җырлыйбыз.

Ләкин нәрсәне булса да матурлау, бизәү, яңа һөнәрләргә өйрәтү аның асылын үзгәртә алмый. Озак еллар буена циркта йөреп, бөтен тамашачының мәхәббәтен яуласа да, аю – аю, арыслан арыслан булып кала. Түтәлдәге чәчәкләр алмагачка да, кешегә дә әйләнми. Без матурлап куйганнан гына аларның хәтта сортлары да, үзенчәлекләре дә әйбәтләнми. Алар, матур итеп киендереп, Сабан туена алып чыккан эт шикелле инде. Матур, тәрбияле, сокланғыч һәм эт.

Без моны барыбыз да күптән беләбез. Аңлыйбыз. Ышанабыз.

Шуннан без тарихка күз салабыз да ата-бабаларның шулкадәр беркатлы, надан, хәтта сантыйрак булуын күреп гаҗәпләнәбез. Нигә шул хәтле этләнеп, бөтен кабиләң белән мамонт куып йөрергә кирәк инде? Ит кирәк булса, аны базардан гына да алып була ич! Базар юк дип… Ясасыннар иде. Аның ни кыенлыгы бар инде, Азиядән, яки Кавказдан берничә кешене китереп, өстәл янына бастырасың да вәссәлам. Алар сиңа нәрсә кирәк, барысын да табып бирә… Үткәннәр турында без һәрвакыт беркатлы итеп, үз чорыбыз биеклегеннән карап һәм шул чорның нечкәлекләрен күрмичә, күргәнен аңламыйча фикер йөртәбез. Шуңа күрә алар безнең чор кешеләренә караганда наданрак, явызрак, акылсызрак булгандыр сыман тоела. Чагыштырырлык та түгел бит инде, чынлап та. Кәрәзле телефоннар, компьютерлар, самолетлар…

Бер караганда, шулай. Ләкин боларның барысы да эткә кидергән киемнәр кебек кенә. Катлаулы аппаратлар да, техника да, хәтта белем белән һөнәр дә кешенең асылын үзгәртә алмый. Кешене тамак хәстәре, җенси теләк, гомер саклау һәм яулау инстинкты идарә итә. Һәм ул нинди генә шартларда яшәсә дә, нинди рәвештә генә хәрәкәт итсә дә шул булачак. Белем, тәрбия кебек феноменнар да бары тик аның рәвешен генә үзгәртергә сәләтле, ә асылын түгел.

Менә монысына без берничек тә ышана алмыйбыз, хәтта аңларга да, белергә дә теләмибез.

Кеше бары тик үзе ышанырга теләгән нәрсәләргә генә ышана ала.

БЕЛДЕРҮ

Диплом бакалавра 101618 0820879, выданный Бабаханову Беку Бабахановичу ФГБОУВО «Казанским национальным исследовательским технологическим университетом» 3 июля 2017 года, считать недействительным в связи с утерей приложения к диплому.

ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ КОЯШЫ

Кайсыгызның кулы җылы?

Күңелне айкый торган чара булды бу. Уйларны әллә кайларга алып китә. Вакыт-вакыт сәхнәдәгеләрнең чыгышларын карап, тормышыңа шөкер итәсең, сәламәтлекнең иң кадерле, кирәкле әйбер икәненә тагын бер кат инанасың. Казанда узган «Һәркемнең үз кояшы бар» («Солнце в каждом») дип аталган физик мөмкинлеге чикләнгән балалар өчен уздырылган I республикакүләм фестиваль минем генә түгел, биш сәгать буе тамаша кылган һәркемнең күңелен йомшартты.

Әлеге сабыйлар тормышны башкача ярата.

Әлеге фестиваль беренче тапкыр гына үткәрелсә дә, катнашырга теләк белдереп, 216 баладан гариза килгән. Арадан «иң-иң»нәрен сайлап алу җиңел булмаган. Оештыручылар күңеленә хуш килгән чыгышлары белән алар Казан сәхнәсен бизәде. Фестивальне «Сандугач» хәйрия фонды оештырды. Фонд президенты Айгөл Хәйруллина әйтүенчә, алар моңа кадәр дә физик мөмкинлеге чикләнгән балалар өчен бәйрәмнәрне күп уздырган.

– Балалар өчен үткәргән чаралар күңелгә рәхәтлек бирә. Аларны сөендерә алуыбызга бик шатбыз. Инде күп еллар авыру балаларга ярдәм итәргә тырышабыз. Быел исә, балаларны бер сәхнәгә җыеп, аларның һәрберсен бүләкләргә булдык. 4 хатын-кыз бергә киңәштек тә, фестиваль уздырыйк, дидек. Без аны дәвамлы булыр, ел саен үткәрербез дип ышанабыз, – ди ул. – Һәр бала үзен зур сәхнәдә күрергә тели. Бу балалар бит әле бөтенләй башка да. Аларның – үз дөньясы. Һәркайсы җиңүче! Иганәчеләр ярдәме белән һәр балага бүләк әзерләдек. Шуңа да без аларның берсен дә кимсетмәдек. Катнашкан берсе дә буш китмәде.

Фестивальгә ярдәм кулы сузучылар күп иде. Аларның барысының да исемнәрен язып та бетерерлек түгел. Хәтта үзләре хакында әйтергә теләмәгән зур йөрәкле эшмәкәрләр дә булды. Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кызлар берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиевага да сабыйларның иҗаты белән танышырга туры килгән. Ул хатын-кыз депутатлар күңеленә хуш килгән балага махсус бүләк бирде. Арбада утыручы Әмир Хәйруллин иде ул.

Җырлы-биюле тамаша башланыр алдыннан балаларны зур экранда Башкортстанда яшәүче, казарма ишелеп, ике аягын югалткан Рөстәм Нәбиев сәламләде.

– Моннан сигез ел элек казарма ишелгәннән соң, инде башка бу якты дөньяны күрә алмам, дигән идем. Әмма мине ышаныч яшәтте. Тормышны яратуым, якыннарымның миңа булган хисләре яшәргә көч бирде. Бүген мин бәхетле. Янәшәмдә сөйгән хатыным, ике кызым бар. Булдырам, дисәң, барысына даирешеп була. Һәркем үзенә ышанырга тиеш. Онытмагыз: безнең дә бәхеткә хакыбыз бар, – диде ул.

Аның чыгышы залда утыручы яшүсмер егетләргә канат куйды кебек. Казанның 78 нче лицеенда белем алучы Әмир Нуриев та Рөстәм кебек булырга хыяллана. Ул максатына таба атлый инде. Шигырьләр яза, аны матур итеп укый, театр түгәрәгенә йөри. Фестивальдә «Кечкенә принц» дип аталган спектакльдән өзек күрсәтте алар. Дуслары да үзе кебек. ДЦП диагнозы булса да, тормыштан зарланмый торган егетләр. Аяклары гына тыңламый үзләренең. Икесе арбада, калганнары кеше ярдәме белән йөри ала. Барысын да бер хыял берләштерә – артист буласылары килә аларның!

Сәхнәдә тамашачыны таң калдырган чыгышлар булды. Арчада яшәүче 8 яшьлек Әдилә Шәфыйкованың җырлавы күңелгә үтте. Биектау районының Дөбьяз авылында яшәүче 18 яшьлек Азамат Агадуллиндагы моң Казан урамнарына да таралды кебек. Балтач районының Чепья авылыннан килгән Кәримә Әхмәтованың бик озын шигырьне бер дә ялгышмыйча җиренә җиткереп сөйләвенә дә куандык. Кыскасы, сәхнәдә чыгыш ясаган һәр баланың җиңүче икәнен аңлап утырдык.

Татар эстрадасы җырчылары да физик мөмкинлеге чикләнгән балалар белән бергә чыгып җырлады. Тамашачы Дилә Нигъмәтуллинаның арбада утыручы Тимур Фазлыев белән бергә җырлавын яратып алкышлады. Миләүшә Сафинаның сәхнәгә кызы Мәрьям белән чыгып җырлавы да сокландырды. Залда «Ватаным Татарстан» газетасында язмышлары бәян ителгән гаиләләр күп иде. Арада сөенече белән уртаклашучысы да булды. Балтачта яшәүче Рәзилә Мәхмүтованың шатлыгы эченә сыймый. Тернәкләндерү үзәгеннән кайтканнан соң кызы Рания тотынып йөрергә өйрәнгән. Өстәвенә кызы кул эше буенча җиңүче дә булган.

Шушы балаларны бәйгегә әзерләгән укытучыларга, әти-әниләренә рәхмәттән башка сүз юк. Ул сүзне сәхнәдән еш кабатладылар. Бу чара концерт карап кына утыруга кайтып калмады, ул безне тәрбияләде дә.

Өйгә җәяү кайтасы килде. Күңелдә – сәхнә тоткан, залда утырган балалар. Иң мөһиме – бу балалар елмая белә. Тикмәгә генә кояшка тиңләмиләр үзләрен. Һәрберсенең күңелендә үз кояшы бар. Ул кояш сүнмәсен, сабыйларны саклап, яклап, җылытып торсын иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сәхнә

Равилә Вәлиуллинаның шәхси архивыннан

ҮЗЕ КЛУБ, ҮЗЕ ТЕАТР

Лаеш районының Кече Елга авылына эш сәфәре белән баргач, авыл уртасында тышына зур итеп «Театр» дип язылган бина күзгә чалынды. Өр-яңа, төзек булып, әллә кайдан ымсындырып тора ул. Гап-гади татар авылы уртасында «Театр» исемле бинаның булуы үзе үк гаҗәп бит. Кереп карыйсы иттек. Баксаң, авылның мәдәният йорты, төзекләндерүдән соң, «Кече Елга үзешчән халык театры» исемен йөртә башлаган икән.

Театрның режиссеры Равилә Вәлиуллина белән дә сүз йомгагын әнә шуннан сүтә башладык. Баштарак театр авылның элеккеге мәдәният йорты бинасында эшләп килгән. Ул чактагы район башлыгы Михаил Афанасьев, төзекләндерү алдыннан клубны карарга килгәч, дивардагы кулдан ясалган афишаларны күреп шакката. Ватманны икегә бүлеп тудырылган әлеге матурлыкка бер сокланса, авылда шундый көчле халык театры эшләп килүгә тагын да гаҗәпләнгән ул. Шул көнне район башлыгы «театрны һичшиксез танытырга» дигән күрсәтмә бирә. Шул рәвешле төзекләндерелгәннән соң яңа мәдәният йорты бинасы «Кече Елга театры» исеме белән ачыла.

– Мин үзем – шушы авыл кызы. 1984 елда авылга кайттым. Үзешчәнлекнең бик көчле чоры иде ул. Беренче спектакльне комиссия караганнан соң, берсе торып басып: «Шушы театрга халык исеме бирик әле», – диде. Шул көннән бирле без Кече Елга үзешчән халык театры булып киттек. 40 елдан артык эшлибез инде, – ди Равилә ханым.

Шушы театрны тудырган, үстергән, шушы дәрәҗәгә җиткергән кеше ул. Нинди генә эшкә тотынса да, төбенә төшмичә тынычланмый торган тынгысыз җан икәне күренеп тора. Театр турында үз баласыдай кадерләп, яратып сөйли. Спектакль сәхнәгә менәр алдыннан уза торган барлык эшләрне үзе башкара Равилә апа.

– Башта пьесаны сайлыйм. Аны яхшылап өйрәнәм, сызам, бозам, тезәм. Анда уйнарга актерларны авылдан, үземнең тирәдәге кешеләрдән туплыйм. Спектакль саен диярлек яңа состав җыела. Әмма бар шундый кешеләр: алар ел да уйный. Балачактан шушы театрда уйнап үсеп, инде үзләре гаилә корып, әти-әни булгач кына туктаучылар да бар. Соңгы елларда спектакльдә уйнарга дип күрше авылдан да килә башладылар, – ди Равилә апа. – Рольгә кеше сайлаганда көн-төн йокламыйсың инде. Сөйләмен, тышкы кыяфәтен дә уйларга, туры китерергә кирәк бит. Спектакльне карагач, тамашачы, ул шулкадәр оста уйнады, диләр. Шулай сайлау нәтиҗәсе бу. Бездә уйнаучы артистларга шулкадәр рәхмәтле мин. Чөнки театр ул – күмәк хезмәт. Анда берүзең генә берни эшли алмыйсың.

Театрда уйнаучылар – һөнәрләре буенча мәдәнияткә бөтенләй дә катнашы булмаган кешеләр. Араларында полициядә эшләүчесе дә, укытучысы, студенты, төзүчесе дә – барысы да бар. Бирегә күңел өчен йөри алар. Әби-бабайлар да уйный биредә.

Театр Кече Елга халкының гына түгел, күрше авылда яшәүчеләрнең дә яраткан урынына әйләнгән. Спектакльләрдә уйнарга да, карарга да бик теләп йөри алар. Премьера вакытында 120 кешелек залда буш урын табам димә. Шуңа кайчак спектакльне өч көн рәттән дә куярга туры килә икән.

– Авыл халкы һәр премьераны түземсезлек белән көтеп ала. «Нәрсә турында булыр икән?» – дип баш вата. Уйнаучыларны ничек яратып карауларын күрсәгез иде сез! Актерлар да үзләрен шулкадәр бәхетле тоя. Авыл халкы рухи азык ала. Спектакль турындагы хатирәләр әле әллә ничә еллар дәвамында кешеләр күңелендә саклана. Мәсәлән, «Әниләр һәм бәбиләр» спектакленнән соң шулай булды. «Диләфрүз», «Гөргөри кияүләре» спектакльләре турында әле һаман сөйлиләр.

Шушы дүрт дистә елдан артык гомер дәверендә Кече Елга сәхнәсендә кырыклап спектакль уйналган. Илгиз Зәйниевнең «Бөке», Ләбиб Леронның «Иман», Ренат Харисның «Казан чибәре» әсәрләре буенча куелган спектакльләр… Саный китсәң, бик күп алар. Кайбер премьераларны әсәрнең авторлары үзләре дә кайтып тамаша кыла икән. Әле бу көннәрдә Кече Елга театры тамашачыларын кабат сөендерергә җыена. Якын арада авыл сәхнәсендә Туфан Миңнуллинның «Алты кызга бер кияү» әсәрен сәхнәләштерәчәкләр.

Кече Елга үзешчән халык театрының иң төп үзенчәлеге дан-шөһрәт артыннан кумаудадыр, мөгаен. Ниндидер зур бәйгеләрдә дә катнашмый алар. Үзләре өчен, күңел өчен уйныйлар. «Авыл халкы өчен генә уйныйбыз. Иң зур бәя – халык мәхәббәте», – ди Равилә апа да. Әнә шушы мәхәббәтне киләчәктә дә әле бик озак саклап, аклап яшәргә язсын аларга!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

ГАДИ ҺӘМ ТАЛӘПЧӘН ИДЕ

Районыбызны ике дистә еллар җитәкләгән Әнвәр Бәдретдин улы Баһаветдинов матбугатны, әлеге җәһәттән район газетасын, ягъни без – журналистларны бик якын, үз итә иде. Үзе темалар тәкъдим итә, еш кына язып-сызып та бирә. Бигрәк тә яшьләргә игътибарлы зур. Берзаман урак өстендә язучы Марсель Галиев туган авылы Балтачта кырда йөргәндә килеп туктады да мине, әле яңарак кына эшли башлаган егетне, «Волга»сына утыртты. Машинасына әрем җәелгән, шундый да якын булып куйды, мин сиңа әйтим. Әнвәр абый комбайнчылар янына туктый, хәл-әхвәл, игенне сукторучылары белән ныклап таныша, «Нинди ярдәм кирәк?» – дип тә сорый. Читтән бер дә күрмәгән кешегә һич тә район башлыгы димәссең, шулкадәр дә гади, эчкерсез, күңелле. «Менә бу комбайнчы абыйларыңны аерым тукталып язарсың инде», – дип тә куйды.

Казаныбызда Әнвәр Баһаветдинов хөрмәтенә хәтер тактасы ачу тантанасында Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев: «Аның белән эшләү минем өчен зур мәртәбә иде. Әнвәр Бәдретдин улы – Ватанга хезмәт итүнең чын үрнәге. Ул республикабыз һәм илебез чәчәк атсын өчен эшләде», – дип тикмәгә әйтмәгәндер!

Әйе, менә ничә дистә еллар үткән, ә Әнвәр абый гүя янәшәмдә – сөйләшеп торабыз сыман. Шулай булырлык та. Берчак районкомда, ул чакларда терлекчелек буенча, аерата сөт савыну арттыру буенча киңәшмәдән соң, мине – яшь журналистны туктатты да:

– Сарлыга барып кил әле, Вагыйз абыең сөтне киметә башлаган – тәртипкә салырга кирәк! – диде.

Һәм икенче көнне иртә белән «Алга» колхозы председателе Социалистик Хезмәт Герое Вагыйз агай Хаҗиәхмәтов кабинетына килеп тә кердек.

– Стәрле егетен җибәрәм, – дип әйткән иде шул Әнвәр Бәдретдинович. – Анда әллә ни борчылырлык хәл юк, азык ташучы трактор көйсезләнеп киткәч, өзеклек булган иде.

Ул арада ферма мөдире Фәрәгать Солтанов та килеп керде.

– Вагыйз абый, барысы да тәртиптә, сөт элекке хәлендә кайтты. Печән дә җитәрлек, башак та пешекләп бирелә, – диде.

Ферма чиннап та ялт итеп тора иде. Килачактә колхоз председателе буласы партком секретаре Габделбари Солтанов та каршы алып, терлекчеләр йортына алып керде. Анда терлекчеләр җыелган.

– Безгә бервакытта да артка калырга ярамый, – диде Вагыйз агай алар алдында. – Яңадан болай кыен хәлгә калмыйк!

Без Рафгать абый белән тырыш ферма эшчәннәрен фотога төшереп алдык һәм «Маягыбыз»ның алдагы санында «Алга»лылар алга атлый» дип фоторепортаж чыкты.

Аннары очрашуыбызда Әнвәр абый: «Әйбәт булган!» – диде дә сорап куйды:

– Кайда торасың соң?

– Фатирым юк әле…

Берничә көннән райкомнан шалтыраттылар.

– Сезгә бер бүлмәле квартира бирелде!

Тагын да очрашуыбыз – райком бюросы утырышында партия әгъзалыгына кандидатлыкка үткәндә.

– «Маяк»та «Яшел аптека» ачарга буладыр? Безгә дару үләннәрен танырга өйрәнергә кирәк! – диде.

Шуннан газетабыз битләрендә күтеп алган «Безнең яшел аптека» сәхифәләре күренә башлады.

Үткән заманнарны сагынып искә алабыз.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Халкым!

Нинди гүзәл, матур минем халкым!
Сәхнәләргә килеп чыга балкып!
Һай, кызлары!.. Сылулардан сылу!
Их, егетләр! Бәхет – татар булу!
Их, туганнар! Бәхет – татар булу!

Нинди гүзәл, матур минем халкым!
Күз карашы күңелемә якын!
Талантка бай һәрбер кызы, улы,
Җырларында сандугачлар моңы!

Нинди гүзәл, матур минем халкым!
Гореф-гадәт, йолалары алтын!
Бәйрәмнәре – нинди олы аның,
Сабан туе әйләнә Җир шарын!

Нинди гүзәл, матур минем халкым!
Кызлар – кояш, егетләре – ялкын!
Шанлы тарих ята тамырында,
Исеме зур, әзле Җир шарында!

Нинди гүзәл, нинди матур халкым!
Яшәр мәңге Җир йөзендә балкып!

Наил КАСЫЙМ

Илдар Мөхәммәтҗанов

ӘТИЕМ НӘСЫЙХӘТЕ

Без гаиләдә җиде бала үстек. Берләребез икенчеләребездән никадәр нарасый булсак, калганнарыбыз шул дәрәҗәдә үк сабый. Шул бәләкәйләр арасында инде үсмердән зураеп, буйга калкып барганы, әнинең дә, балаларның да ышанычы, күз карашы мин идем.

Үз-үземне аңлый, күзаллый башлаганнан бирле бер шәхесне калебемдә йөртәм. Гомернең нинди генә читен, җәйсыз мизгелләре булмасын, башыма нинди генә кайгы-хәсрәтләр килмәсен, кая гына барып, нинди генә гамәл кылсам да, мин күңелемнән шушы шәхес белән сөйләшәм. Дөрес, ул инде күптән бакыйлыкта. Ләкин мин аның белән әле дә киңәшәм, фикерләшәм. Бу бәндәгә мәхәббәтем аның гарәп, рус, латин хәрефләре белән укый-яза белгәне, тырыш, сабыр, бик тә юаш булганы өчен генә түгел, ә күңелнең иң нечкә җепселләрен гафиллектән уятып, үзенә генә хас бер моң, аһәң белән Коръән аятьләре кәлимәләрен кыйраәт дәвамында, үзе тыңлаган һәр бәндәнең калебен Коръән-Кәрим нигъмәте илә уйга салганы, шул исәптән мине дә хәйран калдыра алганы өчендер.

Ул зат, ул шәхес – минем Гыйбадулла исемле газиз бабамның углы, минем бәгырь түрем – әтием Салихҗандыр. Ул бик тә авыр утызынчы-кырыгынчы елларда – вәхшилек хөкем сөргән чорда – утыз меңгә якын дин әһеле Соха тайгаларында, Воркута шахталарында, Ак диңгез – Балтыйк каналларында газапланып үтерелгән заманда – миңа кача-поса гарәп хәрефләрен өйрәтте, Коръәннең беренче сүрәсен – «Ихлас» Шәрифне (колһуалланы) көйләтте.

…Барыннан да бигрәк 1941–1942 елларның кышында әтиемнең Мәскәү өчен фашистлар белән дәһшәтле сугыштан гарип булып кайтуын нык хәтерләм. Сул кулы җилкәсенә әйтерсең лә тагып кына куелган: фашист пулясы беләзектән кергән дә, ярылып, әтиемнең терсәген – итен-сөяген тәмам актарган. Әтинең сәяктән генә торган мускулсыз кулын күргән балалар курыксалар да, гаиләбез башлыгының исән кайтканлыгына куанышттылар. Әни, мәрхүмә, инде күптән бушаган он кисмәгенең төбен кыра торгач, бер чүмеч он юнәтте. Шуңардан төче күмәч (бездә – күмәч, руста лепешка диләр) пешерелеп, һәр балага бирәр генә булса да бәрәңге дә тиде. Әти дә, әни дә, балалар да үзебезгә генә хас кичерешләр белән сөенештек. Ләкин бу сөенеч озакка бармады.

Миңа, уналты яшь тулып җиткән «егет»кә, сугышка китәргә боерган чакыру кәгазе һәрбарчабызга да көенеч булып, гаиләгә кайгы салды. Бер мең дә тугыз йөз кырык дүртенче елның унынчы декабрь иртәсендә туган авылым Балтач төбәгендәге Чутайның картыяше мине сугышка озатты. Барысы да: «Малай гына бит әле», – дип, мине кызгана. Күбесе елый. Тик әтинең дә, минем дә күңелләребез каткан – еламыйбыз.

Булган ризыкларны, бер кием запас чабатаны киндер капчыкка салып, авызын мунчала белән бәйләп куйдык. Әти, мин һәм Низаметдин җизни, өчәүләп, ике рәкәгать сәфәр намазын укыдык. Аннан юлга кузгалдык. Зират капкасы яныннан үтеп барыш. Бихисап күп озатучылар. Әти атны туктатты. Бик җитез адымнар белән зиратка таба ничек барган булса, егерме адым чамасы киткәндер, шул мәлдә туктап калды да, бердәнбер кулы белән ишарәләп, мине үзенә чакырды. Мин килеп җиткәч, әти мине күкрәгенә кочып алды да: «Бу зиратта әбиең вә бабаңның җәсәде ята. Аларның рухын рәнҗетмә. Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтә. Аракы эчә күрмә, тәмәке тартма, командирларыңны тыңла. Бел. Аллаһы хак! Аннан гына сора! Ялвар! Күңелең, җаның-тәнең белән, калебең белән…» – дип әйтүе булды, йөрәк бәгырем үксеп-үксеп еларга тотынды. Минем дә күзләремнән мөлдерәмә яшь бәреп чыкты.

Бу әтинең миңа үгет-нәсыйхәте иде. Әтием нәсыйхәтенә мин һәрчак тугры булдым. Аның фатихасы миңа тормышның теләсә кайсы кыен мизгелләрендә дә таяныч булды. Һичкайчан әти-әниемә, туган нигеземә, илемә кызыллык китерерлек гамәлем булмады. Бу сүзләрне мин зур горурлык, канәгатьләнү белән язам. Татлы сагынуым ул минем.

Харис САЛИХҖАН

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Мөхтәрәм шәхесебез – Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, заманында милиция полковнигы, соңрак дин әһеле буларак киң мәгълүм Харис Салихҗан улы нәкъ менә «һич онытасым юк» сәхифәсе өчен насел-нәсәбенә, яшәү рәвешенә мөнәсәбәтле берничә язма әзерләде.

Шунысына да игътибар итсәгез иде: язмаларда, монысында да, әлбәттә, әкренләп кулланыштан төшеп бара торган сүзләр еш кулланыла, ни аяныч, хәзер инде онытылып та бара. Әйдәгез, Харис ага үрнәгендә хәтер-хатирәләрне яңарту белән бергә халкыбызда кайчандыр киң кулланылышта булып та, онытыла бара торган сүзләрне, әйтелешләрне хәтердә яңартып, редакциягә язмалар юлларга иде. Көтәбез, язмаларның газета битләрендә урын алачагына өмет итәбез.

Бердәмлек бәйрәме

Тынчәлебез алтын баганалы

Һәрвакыттагыча, быел да Халыклар бердәмлеге көнен матур итеп, әнтәлекле, истә калырлык, һәркем сокланырлык итеп билгеләп үттек. Иртән үк куктә кояш балкуы да күңелләргә җылылык, илһам өстәде.

Заманында Яңа Тинчәледә канат чыгарган, яхшы тәрбия, белем алган, хезмәткә өйрәнгән, хәзер инде республикабыз үсешенә, бердәмлегенә зур өлеш кертүче читтәге авылдашларыбыз белән дә без бик нык горурланабыз, шөкер, алар авылга әзне суытмыйлар. Мөхтәрәм шәхесләребезне авылдашларыбыз: «Алар – безнең алтын баганаларыбыз», – дип сагынып көтеп ала. Алар үзләре дә бик гади, рәхәтләнеп сөйләшәләр-серләшәләр, хәтер яңарталар.

Татарстанның финанс министры, авылдашыбыз Радик Рәүф улы Гайзатуллинның бәйрәм чараларына талантлы җыр-моң иясләрен авылдашларыбыз хозурына чакыруы да күркәм гадәткә әверелде. Бу юлы сәхнәне Ришат Төхвәтуллин, аның хәләл җефете Алия Карачурина-Төхвәтуллина һәм аларның төркеме бизәде. Шыгрым тулы зал өч сәгать дәвамында аларга кушылып җырлады, моңланды, рәхәтләнеп алкышлады.

Читтәге мөхтәрәм авылдашларыбызның күркәм үрнәге җирле халкыбызга да көчә. Фермер Фәнис Шәрәфетдинов шулай ук хезмәт кешесен хөрмәтләве белән ихтирам яулый. Бу юлы фермер хуҗалыкның алдынгы өч хезмәткәренә җиңел машина ачкычлары тапшырды. Өр-яңа машиналар үз хуҗаларын мәдәният йорты ишеге төбендә көтеп тора иде. Машиналы булучылар да, авыл халкы да шатлыкларын яшермәде, уен-көлке, бер-береңне данлау урамда да дәвам итте.

Фермерыбыз Фәнис әфәнде хәрби операциядә катнашучыларга да зур суммада ярдәм күрсәтте инде. Авылны тәзекләндерүдә дә аның булышлыгы зур.

Бәйрәмдә район хакимияте башлыгы Ранис Рафис улы Камартдинов һәм аның гаиләсенең катнашуы да ямь өстенә ямь булды. «Районыбызда утыздан артык милләт вәкиле бик дус, бердәм, тату гомер итә, – диде ул. – Бездә итальян да, немец та бар. Бердәмлек, уңганлык-булганлык күркәм җимешләрен дә бирә».

Безнең якларга килгән һәркем юлларыбызга, инеш-чишмәләребезгә, бакчалардагы муллыкка, яшеллеккә, туфракның уңдырышлыгына сокланыун яшерми, бу якларга мин тагын киләм әле, дигән теләк белән китә. Бердәмлек көнендә сәхнәгә республиканың шулай ук мөхтәрәм шәхесе – авылыбызны яшелләндерүгә зур өлеш керткән кеше күтәрелде һәм… күңелләрге «сер»ен чиште. Ә аңарчы ул Радик Рәүф улыннан безнең якларда пешерелгән әпәй, безнең якларда әзерләнгән шәкәр (үзебезнең төбәктә әйтелгәнчә яздым), бал кабул итеп алган иде. «Сер» дигәне болайрак: «Яңа Тинчәледә миңа хәләл җефет табып булмасмы икән?» Зал алкышлады, җирле үзидарә җитәкчесе Радик Камил улы Мадышев исә теләк-ниятне күңеленә сеңдерде, тора-бара димче булып та китмәгәе әле. Изге ниятне гамәлгә ашыручы, һәркемнең гозерен тыңлап, үтәргә омтылучы, тырышлыгын, көчен, авылны, анда яшәүчеләрне саклауга юнәлткән, уңган-булган авылдашыбыз ул Радик әфәнде.

Безне бердәмлек-бергәлек яшәтә, горур итә.

Гөлгенә ГАЙЗАТУЛЛИНА,
Буа районы Яңа Тинчәле мәктәбе директоры

Гаиләбез истәлекләре

Оекбаш

Хәтерлим: йон оекбашлар тишелгәч, әнием аларны ямый иде. Берәр пар булырлар иде инде алар һәрберебезгә. Шуңа күрә ямап бетергәнен көтеп утырган чаклар да булды. Әнием кулыннан алып, аякка киеп куйган оекбаш шундый җылы була торган иде! Әниемнең кул җылысы күчә иде аңа. Әниемнең бу эшенә мин бик кызыга идем. Тиктормас аякларда тишелә башлаган оекбашларны кабат тишексез киеп кую ошый иде миңа.

Бик кечкенә чакта минем дә оекбаш ямыйсы килгәнен хәтерлим. Ничек кирәк алай энә, йон юнәтеп, ямау салдым. Шул оекбаш белән бутый (резин аяк киемен шулай дип йөртә идек) киеп, урамда уйнадым. Өйгә кайткач, аяктан бутыйны салганда ямаулыгым бутый эченә төшеп калганын белдем… Беренче тапкыр ямау салу шулай тәмамланды.

Кыска кунычлы яшел бутый

Студент чак. 1970 нче еллар. Пединституттның беренче курсында укыйм. Шимбә саен авылга, әнием янына кайтып йөрим. Көз көне. Бер кайтканда, әнием миңа дип авыл кибетеннән резин итек, әлеге дә баягы «бутый» алып куйган. Элекке резин итекләрдән аермалырак иде ул. Резинадан эшләнгән дип тә әйтеп булмый, җиңелрәк иде. Кыскарак кунычлы, җете яшел төстә. Әнием шатлыгыннан нишләргә белми, чөнки ул вакытта аяк киемнәренә, гомумән, бар нәрсәгә кытлык. Ул аны, авыл кибетләрендә бик сирәк була торган аяк киемен, миңа дип үтенеп сорап алган. Ике пар гына кайткан булган кибеткә. Минем аклы сызыклар төшкән кара пальтома ямь-яшел төстәге «бутый»лар… Мин башта ни әйтергә белми сүзсез калдым. Эчтән генә уйлыйм: «Миңа дип алган… Шатланган… Минем өчен шатланган… Кызым матур бутыйлы булды дип шатланган әниемнең күңелен төшерәмме соң!» «Бик зур рәхмәт сиңа, әнием!» – дидем дә, ничегрәк, нәрсә белән киярмен икән дип уйлый башладым…

Җаен таптым. Йон җепләрдән яшелле-аклы баш киеме, шарф, яшел җептән перчатка бәйләп киеп йөрдем мин аклы-каралы пальтомны ул ямь-яшел бутыйлар белән…

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Халык әйтсә, хак әйтә

Дуслар белән юл кыскарак.

***

Йөз сумың булганчы, йөз дустың булсын.

***

Балык сусыз тора алмый, кеше дуссыз тора алмый.

***

Бердәмлектә – көч.

***

Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел.

***

Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.

***

Дуслык – зур байлык.

***

Кош – канаты белән, кеше дуслык белән көчле.

***

Дуслык тау күчерә.

***

Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – югалтма.

***

Кумәк күтәрсә, күлне күчерер.

***

Ялгыз агачны җил сындыра.

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юлларга әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга сокланү, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыруны дәвам иттерәбез. Аның чираттагысын шүвырга багышлыйбыз. ШҮВЫР – мари халкының традицион уен коралы, Идел-Чулман төбәгендә яшәүче төркиләр һәм фин-угорларда киң таралган куык сорнайның бер төре. Бүген без аның мисалында мариларның милли уен коралларының үзенчәлекләре, үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшербез.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

АЛЕКСАНДР СЛАВИН:

«ЯШЬЛӘРГӘ КЫЗЫК ИКӘН, КИЛӘЧӘГЕ БУЛАЧАК»

Шүвыр һәм, гомумән, мари халкының традицион уен кораллары нәрсәсе белән үзенчәлекле? Яшь буын алар белән кызыксынамы? Кызыксынсын өчен, нишләргә? «Лай мардеж» һәм «Озан мари» ансамбльләренең музыкаль җитәкчесе, «Казан шәһәре мариларының милли-мәдәни автономиясе» җирле иҗтимагый оешмасы вәкиле Александр СЛАВИН безнең шул һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

:: «Лай мардеж» һәм «Озан мари» ансамбльләренең үзенчәлеге нидә?

– Безнең барлыгы өч ансамблебез бар. Балалар өчен махсус төркем оештырдык. «Лай мардеж» яшьләр ансамбле булуы белән үзенчәлекле. «Озан мари» исә – өлкәннәрдән торган фольклор коллективы. Әйе, чыгышларыбызда милли уен коралларын да күрсәтергә тырышабыз. Шүвыр, гөслә, мари барабаннары – кысказы, мари халкының төп инструментларын файдаланабыз. Кызганыч, хәзер тере тавышка гына чыгыш ясау авыррак. Шуңа да без милли колоритка бай булган аранжировкалар да ясыйбыз.

> Көйләребездә милли уен коралларының тавышы булу ансамбль өчен бик мөһим. Гасырларны кичкән тавыш, янгыраш бит ул! Мин үзем Казан мәдәният институтының халык уен кораллары бүлеген тәмамладым. Хәзер инде белгәннәремне башкаларга өйрәтергә тырышам.

:: Ансамбльләр белән еш чыгыш ясыйсызмы?

– Шәһәр күләмендәге чараларны, милли бәйрәмнәрне калдырмаска тырышабыз. Шулай да, еш чыгыш ясыйбыз, дип тә әйтеп булмый. Фестиваль- конкурсларда катнашабыз. Һәм, әлбәттә, мариларның Семык бәйрәмен ел да көтеп алабыз – анда да чыгыш ясыйбыз.

:: Шүвыр һәм, гомумән, мари халкының милли уен кораллары нәрсәсе белән үзенчәлекле?

– Иң беренче чиратта янгырашы белән. Әйтик, бездәге шүвыр (ягъни волынка була инде) һәм барабан башка халыкларда да бар. Ләкин тавыш, янгыраш ягыннан марнларныкы аерылып тора. Бу аларның төзелешенә бәйле.

> Башка халыклардан аермалы буларак, марилар шүвырны традицион рәвештә үгез яисә ат куыгыннан ясаган. Шуңа да ул кечерәк булган, тавышы да ул кадәр янгырамаган. Аның атамасы да «шовыронг», ягъни «сидек куыгы» сүзеннән ясалган.

:: Татарстанда мариларның традицион уен коралларын ясаучы осталар бармы?

– Кызганыч, Татарстанда осталар калмаган. Милли уен коралларын ясый белгән буын киткән, яшьләр исә бу һөнәргә үз вакытында өйрәнмәгән. Шул рәвешле чылбыр өзелгән. Хәзер инде уен коралларын фәкать Йошкар-Оладан алып кайтабыз.

:: Гел читтән кайтарту җиңел түгелдер?

– Зур проблема димәс идем моны. Күтәргә кирәк – шул гына. Осталар, гомумән, аз калды. Булганнарының заказлары күп. Шактый озак көтәргә туры килә. Әйтик, шүвыр ясар өчен бер елдан артык вакыт кирәк булырга мөмкин.

:: Уен коралларына карата булган кызыксыну, аларны ансамбльнең бер өлеше итү каян килә?

– Халык уен коралларында уйный белүчеләр елдан-ел кими. Онытасы, югалтасы килми бит… Яшьләрнең

кызыксынуы сөендерә, әлбәттә. Хәзерге яшьләр кызыксына икән, аларның киләчәге булачак. «Марийская радуга» проекты кысасында балалар белән уздырыла торган мастер-классларыбыз әнә шул максатларны күз уңаенда тота да инде. Аннан соң, милли хисләрдән тыш, профессиональ музыкант буларак та кызык бу миңа.

:: Яшь буын кызыксына, димәк?

– Балаларда, яшьләрдә кызыксыну бар. Ул каннарына сеңгәндер дип уйлыйм. Күпме гасырлар дәвамында ата-бабаларыннан калган традицияләр бит ул!..

:: Шүвырның киләчәге кем кулында?

– Шүвырның да, гомумән, милли уен коралларының киләчәге – безнең кулларда.

Заманча технологияләр чорында традицияләренне я бөтенләй онытырга, я киресенчә, аңа ясуллар ярдәмендә, аңа яктан өйрәнергә була. Кайсы юлны сайлыйсың бит.

:: Аларның киләчәге булсын өчен нәрсә эшләргә кирәк?

– Бу җәһәтән фестивальләр, онлайн һәм «ачык дәрес»ләр, кызыклы форматтагы концертлар, гомумән, балалар һәм яшьләр теләндәге контент кирәк. Яшьләр тыңлый торган көйләрне дә милли уен кораллары белән баетып җибәрсән, бу да кызыксынуны арттырыр иде.

Бу кызык!

- Заманында шүвыр марилар яшәгән һәр авылда булган. Борынгы заманнарда аны күбесенчә ритуаль йолалар вакытында кулланганнар.
- Борынгы заманнарда әлеге инструментта уйнаучының кошлар һәм җәнлекләр телен аңлавына ышанганнар.
- Язын марилар шүвырда уйнап, дога кылып, кырлар буйлап йөргәннәр, уңай һава торышы теләгәннәр. Җәй урталарында шундый йола тагын кабатланган: бу юлы, шүвырда уйнап, яхшы уңыш теләгәннәр.
- Туйларда да, кешене соңгы юлга озату мәрасимендә дә шүвырда уйнаучы түрдә булган. Аның тавышын «чистарыну»га тиңләгәннәр.
- Әлеге уен коралы җеннәр куу йоласында да кулланылган.
- Шүвырда элек-электән бары ир-атлар гына уйнаган.
- Өендә әлеге уен коралы булган гаилә, күченгән очракта, аны да үзләре белән алган, шүвырны нәсел ядкәре буларак саклаган.
- Мари халкында шүвыр тавышын озаклап тыңлаган кеше транска китеп, авыруларыннан арына ала дигән ышаныч яши.

Фикер

Людмила МУСИХИНА, «Казан шәһәре мариларының милли-мәдәни автономиясе» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе:

– Марилар яши торган һәр районда традицион уен кораллары бар. Грантлар отабыз, аңа уен кораллары кайтартабыз, анда уйнарга теләүчеләр бар. Әмма Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен коралларында уйнарга өйрәтүчеләр, аерым алганда, уку йортларында махсус булекләр юк. Бу өлкәнең төп проблемасы шул. Уен коралларының тарихын яхшы белгән, аларда уйнау серләрен башкаларга өйрәтә алган остазлар җитми. Ә теләк белдерүчеләр, әйткәнемчә, бар. Ин беренче чиратта, музыкаль белем бирү процессын көйләргә иде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе доценты

Идел-Чулман төбәгендә яшәгән халыкларның сәнгати мирасында тирәдән эшләнелгән күрек капчыкка, яисә мал куыгына ике сорнай көпшәсе беркетелгән музыка коралында уйнау традицияләре барлыгы билгеле.

Бу уен коралы тарихын тикшергәндә күп кенә моңа кадәр билгеле булмаган мәгълүматлар ачылды. Гамәлдән чыккан булса да, аның турында фактик материаллар бай һәм кызыклы. Димәк, тере традицияләре калмаса да, аны тергезеп, яңадан кулланышка кертү мөмкин. Моның өчен, беренчедән, булган материалларга нигезләнеп, фәнни-гамәли тәҗрибәләр үткәреп, бу коралны ясау, икенчедән, уйнау өчен репертуарын, башкару стилен дәлилле итеп реконструкцияләү һәм халык алдына чыгару кирәк.

Узган кырык елдан артык этнографик экспедицияләрдәге күзәтүләр, чагыштырмалы тикшеренүләр үткәрү нәтиҗәсендә шуны әйтергә була: бу музыка коралы элекке заманда Идел-Чулман буйларында яшәгән барлык халыкларда да кулланышта булган. Аны төрле төбәк сөйләшләрендә шыбыр, сорнай, кубыз, бызгы дип атаганнар. Руслар аны волынка диләр. Идел-Чулман төбәгендә яшәүче руслар тарафыннан куык сорнайларны пузырь дип атау гадәте дә киң таралган.

Татарларның төрле сөйләшләрендә һәм алар белән этник-мәдәни элемтәдә булган башка халыклардагы куык сорнайларның исем-атамаларын чагыштырып карыйк.

Шыбыр (тат.), шăппăр (чув.) һәм шүвыр (мари) – Идел-Чулман төбәгендә (төркиләр һәм фин-угорларда) киң таралган куык сорнай исеме. Бу хәл төбәктә башка исемнәр белән чагыштырганда иртәрәк барлыкка килүенә бәйле булуы мөмкин.

Куык сорнайларның татар мәдәниятенә бәйле булу мәсьәләсен ачыклауда XIX йөздә миссионерлар тарафыннан филология һәм этнография буенча материаллар бер микъдар күләмдә ярдәм итә.

Парлы уен көпшәле төрек сорнаеның (тулум, тулуг зурнасы) гомуми күренеше. [Tarlabaşi Burhan. Öz çalgımız kaval. – Istanbul, 1984. исемле китаптагы рәсемнән карап төшерелде]

Идел-Чулман төбәгендә шүвыр коралының үзе һәм атамасының беренчел чыганагы булып Урта һәм Ерак Көнчыгыш халыкларының борынгы тынлы музыка коралы булуы мөмкин. Борынгы Иранда кулланылган тынлы уен коралының атамасы – шайпур, Сириядә – шифора. Әлеге уен коралы һәм аның атамасы Идел-Чулман төбәгендә борынгы фарсы телле скиф-сармат кабиләләре белән үзара этник һәм мәдәни элемтәләр нәтиҗәсендә барлыкка килүе мөмкин.

> **Шүвыр атамасын марилардан тыш башка фин-угор телле халыклар кулланмый. Димәк, мари лексикасында бу сүз борынгы фин-угор берләге таралган вакытта һәм скиф-сармат мәдәнияте тәэсире көчле булган җирле төрки кабиләләр белән аралашу нәтиҗәсендә барлыкка килүе мөмкин.**

Төрки телле этник төркемнәрдән аны чуашлар (шăппăр) һәм керәшеннәр куллана (шыбыр).

Кыргыз-казакъларның күрек сорнайлары да Европа үрнәкләреннән аерыла һәм күп сыйфатлары белән Идел-Чулман халыкларының шундый ук коралына якын. Күчмә төркиләр буларак казакъ-кыргызлар күптәнге заманнардан бирле Идел-Чулман халыкларының күршеләре булып яшиләр. Казакъларның күрек сорнае турындагы Павел Юдин (1864–1928) үзенең «Киргизы» атамалы этнографик язмасында бик сирәк тасвирлама бирә: «…казахская волынка состояла из двух коротеньких дудочек из камыша, приделанных к бычьему пузырю, а извлекаемая музыка по звучанию напоминала звуки волынки».



Бер көпшәле казакъ сорнаеның (желбуаз) гомуми күренеше. [«Казахские народные музыкальные инструменты». – Алма-Ата: Изд-во «Өнер», 1986. исемле китаптагы рәсемнән карап төшерелде]

Шунысы шиксез: куык сорнайлар Идел-Чулман төбәгендә төбәк күренеше статусына ия һәм аларның һәрбер төбәктә аерым үзенчәлекләре булган. Әгәр дә бу тарихи уен коралын реконструкция аша яңадан тергезеп, сәнгать әйләнәсенә кертү гамәле тормышка ашырылса, бу адым, әлбәттә, тулысынча элеккеге сыйфатларын кабатлый алмаса да, тарихи эзлеклелекне дәвам итә торган бер күркәм омтылыш була алыр иде.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 350

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+